• КЫЙССА •
ЮНЫС ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ
*5 бит*

• МӨСЛИМӘ •
АНА – БӨЕК ИСЕМ
*7 бит*

• НӘСЫЙХӘТ•
СӘФӘРГӘ ЧЫГУЧЫ КЕШЕ
*12 бит*

• ӘДӘБИ СӘХИФӘ •
КАЙНАР ДИҢГЕЗ ЮЛЫ
*14 бит*

*№ 11 (304)* *Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы* *Рабигыль-ахыр 1442*

*Ноябрь, 2020*

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ




Динебез әниләргә карата игътибарлы булырга, аларны хөрмәт итеп яшәргә боера. Шулай ук әниләрнең дә балалары алдында үз бурыч-вазифалары бар. Әни кеше баласын кечкенәдән дөрес тәрбияләгән очракта, олыгайган көннәрен күңел тынычлыгы белән каршы алыр.

***Дәвамы 7 нче биттә***

Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръән аятьләре булганлыктан, басмага игътибарлы булыгыз!

12+

# Гыйбадәт бүлмәләре булдырылачак

**Татарстан Президенты Казанның сәүдә үзәкләрендә гыйбадәт бүлмәләре булдыру тәкъдимен хуплады**

16 нчы ноябрь көнне, ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Сәүдә-сәнәгать палатасында Татарстан эшкуарлары белән очрашты. Әлеге чарада эшмәкәрләрдән тыш, хакимият вәкилләре, төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр, шул исәптән Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да катнашты.

Очрашуда Covid-19 пандемиясеннән зыян күрүчеләргә ярдәм ихтыяҗы булу-булмау турында фикер алышудан тыш, күп кенә башка мәсьәләләр дә кузгатылды. Шуларның берсе – Казанның сәүдә үзәкләрендә мөселманнар өчен өстәмә гыйбадәт бүлмәләре булдыру. Әлеге фикер белән очрашуда РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе президенты Айдар Шаһимәрданов чыкты. Ул Ассоциациянең мондый намаз уку бүлмәләрен «Сувар Плаза» һәм «Караван» сәүдә үзәкләрендә оештыру тәҗрибәсе барлыгын әйтте һәм мондый башлангыч Halal LifeStyle үсешенең мөһим өлеше булып торуын ассызыклады. Моннан тыш, Айдар Шаһимәрданов РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе гыйбадәт бүлмәләрендә ремонт ясау, аренда һәм коммуналь түләүләрне үз өстенә алыр, дип белдерде.

Әлеге тәкъдимне Рөстәм Миңнеханов хуплап чыкты һәм очрашу барышында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинга гыйбадәт кылу урыннары кирәк булган объектлар исемлеген төзү бурычын куйды.



# Казан имамнары өчен дәресләр узды

**Әбү Даби мөфтие Казан имамнарына фәтвалар чыгару турында лекция укыды**





16-18 нче ноябрь көннәрендә “Рәшидә” ислам дини уку-укыту үзәгендә имамнар өчен “Дини радикализмны кисәтү мәсьәләләре: теория һәм практика” программасы буенча дәресләр узды. Радикализм нигезләре буенча беренче дәресне дүшәмбе көнне ислам фәннәре докторы, Әл Әзһәр мөгаллиме Хәмдәллә Ибраһим Әс-Сафти алып барды.

Аңа кадәр исә Әбү Даби мөфтие, шәех Мөхәммәд Әсләм фәтвалар чыгару үзенчәлекләре буенча лекция укыды. Әлеге очрашуда Казан шәһәренең Совет районы мөхтәсибәте имамнары катнашты. Шәех фәтва бирүчегә (ягъни мөфтигә) куелган таләпләрне санап узды: ул Коръән, сөннәт, иҗмаг, кыяс фәннәрен, зур галимнәрнең китапларын һәм риваятьләрен яхшы белергә тиеш, ә үзенең сыйфатларына килгәндә – иң мөһимнәреннән гыйлемне яратуы, ашыкмавы. “Шәһрәт казану, кеше алдында мактану өчен дини карарлар чыгарырга ярамый. Авыруны дәвалау өчен без табибка барабыз, өй төзисе булса инженерга мөрәҗәгать итәбез. Әлеге белгечләр шөһрәт казану өчен түгел, җәмгыятькә файда китерү өчен хезмәт итәләр. Һәр кеше үз өлкәсендә белгеч булырга тиешлеген бөтенебез дә беләк. Мәсьәләне тирәннән өйрәнмичә, ашыгып, грамоталы, акыллы, белемле булып күренергә теләүчеләрнең фикереннән сак булырга кирәк – бу мөселман җәмгыятендә төрле проблемаларга, аңлашылмаучанлыкларга китерергә мөмкин. Шөһрәт өчен кычкыручылар тиз арада үз фикерләрен белдерәләр, алар сорауны тикшерү белән шөгыльләнми. Шуңа рәсми мөфтинең сүзен тыңларга, аның фәтвасына буйсынырга кирәк. Бу безне җәмгыятьтәге төрле яман күренешләрдән саклаячак, экстремизмнан кисәтәчәк”, – дип белдерде. Очрашу кунагы бары мөфти генә фәтва бирергә хокуклы дип ассызыклады. Лекция тәмамланганнан соң имамнар Мөхәммәд Әсләмгә үзләрен кызыксындырган сорауларын бирде. Шәех хәләл туклану, хаҗ кылу, гыйбадәт мәсьәләләре буенча җавапларын ирештерде.


Аннары укулар гакыйдәнең актуаль мәсьәләләре, дини оешмаларның юридик сораулары һәм экстремизмны кисәтү темасы буенча узды.

■ **dumrt.ru сайтыннан**

# 150 000 данә китап нәшер ителгән

**2020 елның 10 ае эчендә “Хозур” нәшрият йорты 65 исемдәге төрле китаплар бастырды**

Рәсәйдә иң эре мөселман нәшриятларыннан саналган “Хозур” нәшрият йорты 2020 елның 10 ае эчендә 65 исемдәге төрле китап бастырды. Аларның гомуми тиражы 150 000 данәне тәшкил итә. Басмаларның актуальлеген һәм укучылар арасында популярлыгын аларның сатылу күрсәткечләре дәлилли: китапларның 110 меңгә якыны сатылды. Бестселлерлар рәтенә “Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә” һәм “Калям шариф. Перевод смыслов” керә.




Билгеле булганча, Диния нәзарәтендә 2013 елда барлыкка килгән “Хозур” нәшрият йорты мөселман медиахолдингы сыйфатында да эшләп килә. Аның мәйданчыгында берничә массакүләм мәгълүмат чаралары чыга. Мисал өчен, агымдагы елның 10 ае эчендә рус телендә нәшер ителә торган “Умма” газетасы 30 000 данә гомуми тираж белән, торгызылган мәшһүр “Дин вә Мәгыйшәт” газетасы 50 000 данә гомуми тираж белән һәм инкыйлабка кадәр чыгып килеп, имамнар өчен янәдән бастырыла башлаган “Шура” журналы 20 000 данә гомуми тираж белән басылып чыкты.

Моннан тыш, “Хозур” нәшрият йорты интернет челтәрендә 7 онлайн-проектны чыгарып бара. Алар – Islam-today.ru (аны ел дәвамында 27 миллион кеше кереп укыды), Huzur.ru, Huzurtv.ru, Azan.fm, Huzurshop.ru, Darul-kutub.com электрон китапханәсе (2020 елда 102 иске китап, электрон форматка күчерелеп, сайтта урнаштырылды. Бүгенге көндә сайтта 1200 дән артык иске татар телендә дини китап бар), Terrora-net.ru сайтлары. Социаль челтәрләрдә исә, 1 нче ноябрьгә алынган мәгълүматларга караганда, “Хозур” нәшрият йортының – 32 һәм Диния нәзарәтенең 5 аккаунтына язылучыларның гомуми саны 2 460 444 кешене тәшкил иткән.

2020 елда эшчәнлектә төп басым “Хозур ТВ” телевидениесенә ясалды. Быел анда 45 тапшыру, 1120 чыгарылыш әзерләнде, аларның гомуми күләме 300 сәгатьне тәшкил итте. YouTube сервисында контентны карау саны 180 млн 871 меңнән артып китте.

2020 елда “Азан” интернет-радиосы тулаем татар теленә күчте. Эфирга якынча 18000 тапшыру чыгарылды. Яңа профессиональ студиядә әзерләнгән проектлар хәзер «Тәртип Fm» һәм «Күңел» радиостанцияләрендә дә яңгырый.

Гомумән алганда, Диния нәзарәтенең “Хозур” нәшрият йорты мәгърифәтчелек, экстремизм һәм террорчылыкны кисәтү, фәнни, дини һәм тарихи әдәбият нәшер итү, татар дини мирасын саклау һәм популярлаштыру; мөселман медиапроектларын тормышка ашыру һ.б. өлкәләрдә эшчәнлек алып бара.

■ **dumrt.ru сайтыннан**

# МОНДЫЙ ХӘЛЛӘР БҮТӘН КАБАТЛАНМАСЫН

Күптән түгел Кукмарада булган бер аяныч хәл районыбыз халкын гына түгел, бөтен республика җәмәгатьчелеген пошаманга салды: Виталий Антипов атлы 16 яшьлек малай яндыра торган катнашма кулланып, башта үзәктә урнашкан кафега, соңыннан шәһәрнең полиция бүлекчәсе янындагы машинага һәм хәтта бинага да зыян салмакчы була, аннары полиция хезмәткәрләренә пычак белән һөҗүм итү сәбәпле, тоткарлау вакытында үтерелә. Ни кызганыч, үзенең шушы явыз гамәлен җинаятьче дини шигарьләр артына ышыкланган булып, мөселманнар исеменнән башкара. Шул уңайдан Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин шул ук көнне, әлеге хәлгә мөнәсәбәтен белдереп, болай дип әйтә:

– Тумышы белән Алтай өлкәсеннән чыккан, Татарстанга килеп урнашканчы Удмуртия һәм Башкортстанда яшәгән бер яшүсмер, җимергеч ят идеологиягә ияреп, бүген тәнлә Кукмарада полиция бүлегенә һөҗүм итә. Үзенең теракт булып саналган куркыныч гамәлен тормышка ашыру өчен ул безнең республика җирлеген сайлый. Бу үсмер республикабызның бер генә мәчетенә дә йөрмәгән, югыйсә, күңеленә хак дин нурын сеңдерә алган булыр иде. Шул рәвешле, террорист, кешеләрнең гомерләренә кизәнеп, җинаять кылып кына калмыйча, күркәм, изге һәм саф динебезнең мәңгелек һәм бөек кешелеклелек кыйммәтләренә кара тап төшерде. Бу коткы үзенең тискәре йогынтысын ясамас, дип өметләнәм, чөнки Татарстан халкы исламны бары тик тынычлык, игелек һәм шәфкатьлелек дине итеп күрә...

Шулай итеп, мөфтиебез Татарстан мөселманнарының шушы вакыйгадан тетрәнеп калуын һәм терроризм белән экстремизмның теләсә нинди чагылышына һәм рәвешенә кискен каршы торуын белдерде.

Мөхәммәд пәйгамбәрнең кешеләргә җибәрелүнең максатын аңлатып, Аллаһы Тәгалә Коръән китабында болай ди: **“Әй Мөхәммәд, без сине барча галәмнәргә рәхмәт итеп җибәрдек”.**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:107

Шуны истә тотып, мөселманнар ислам динен тарату һәм башкаларга җиткерү эшендә көчләү-куркытуны һәм бигрәк тә нинди дә җәберзолымны кулланырга тиеш түгел, чөнки әлеге алымнар динебезгә һәм иман-ышанычка карата кеше күңелендә фәкать тискәре хисләр генә уята, ә ислам дине – ул мәхәббәт һәм мәрхәмәтлелек дине. Шуңа күрә галимнәр исламга өндәү куркыту, һөҗүм итү, җимерү һәм үтерү юлы белән түгел, ә хикмәт, кешелеклелек, сабырлык, шәфкатьлелек һәм башка шундый күркәм сыйфатлар ярдәмендә башкарылырга тиеш дип өйрәтә. “Әлү-Гыймран” сүрәсенең 159 аятендә Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллэллаһу галәйһи вә сәлләмгә: **“Аллаһының рәхмәте белән син кешеләргә карата миһербанлы булдың. Әгәр дә син аларга рәхимсез (дорфа, каты күңелле) булсаң, һичшиксез алар синнән качарлар иде”,** – дип әйтә.

Шушы аятьләрдән билгеле булганча, пәйгамбәребез Мөхәммәд диндә булмаганнарны җәберләр, үтерер һәм юк итәр өчен түгел, ә гыйлем вә хикмәт белән йомшак өндәү ярдәмендә аларга динебезнең матурлыгын, әһәмиятен һәм кирәклеген аңлатыр өчен килде. Ә начарлык эшләп, бигрәк тә Аллаһы Тәгаләнең исемен атап нинди дә явыз гамәл кылу ул барлык ихлас иманлы, чиста күңелле мөселманнарга кара тап төшереп, саф динебезгә зыян гына китерә.

Бүген илебездә ислам дине үсеше өчен барлык шартлар тудырылган: республикабызның һәр авылында диярлек мәчет бар, башлангыч һәм урта һөнәри дини белем бирә торган уку йортлары эшләп килә, Рәсәй Президенты хуплавы һәм булышлыгы белән берничә ел элек ислам докторлары дәрәҗәсендә галимнәр әзерли торган Болгар ислам Академиясе ачылды, теләгән кеше югары дин белеме алыр өчен чит илгә дә бара ала. Республикабызда дини китаплар, газет-журналлар нәшер ителә, Корбан һәм Ураза гаетләрендә халыкка ял көне бирелә. Гаиләдә дин тотып, ислам кануннарын үтәп, ягъни намаз укып, ураза тотып яшәргә дә беркем тыймый. Мондый шартларда ризасызлык белдерү һәм бигрәк тә “исламны яклау” нияте белән кемгә дер һөҗүм итү, башка куркыныч гамәлләр кылу бөтенләй кирәкмәгән, артык һәм ахмак нәрсәдер.

Шәт ин шә Аллаһ, районыбызда булган үкенечеле вакыйга миһербанлык, кешелеклелек белән сугарылган динебезнең һәм намуслы, ихлас гыйбадәт кылучы мөселманнарның дәрәҗәсен төшермәс, һәм киләчәктә мондый аяныч хәлләр бүтән кабатланмас дип өметләнәбез.

■ **Ришат хәзрәт Курамшин,**
**Кукмара мәдрәсәсе мөдире**

# Туган илне яратып яшәүнең мөһимлеге

Төзек һәм дөрес җәмгыятьнең нигезен камиллеккә, яхшылыкка омтылган кешеләр тәшкил итә. Һәр кешенең күңелендә туган җиренә, туган иленә карата мәхәббәт, аның белән горурлану була. Ниндидер сәбәпләр белән, кеше моны никадәр генә инкяр итәргә тырышса да, күңеле, йөрәге белән моның шулай икәнен таный. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ватанны сөю – иманнан», – диде. Динебез буенча без һәр адәм баласының фитри иман белән дөньяга туганын беләбез. Иман – ул күңел белән ышану. Иманлы кеше Аллаһы Тәгаләнең барлыгына, берлегенә, фәрештәләргә, изге китапларга, Аллаһыдан җибәрелгән пәйгамбәрләргә, тәкъдиргә ышана. Кеше никадәр генә үзен фитри иман халәтеннән аерып карарга, тәкәбберлек белән үзен болардан өстенрәк куярга тырышса да, аның күңел түрендә яхшылыкка, чисталыкка һәм Аллаһының киң кодрәтенә ышану яши. Шуңа да «Ватанны сөю иманнан» дигән хәдистә кеше барыбер туган илен ярата дигән фикер белән беррәттән, мөселман кешесе Ватанын яратырга, аны кайгыртып яшәргә тиеш дигән фикер уза. Бу бик тә мөһим, чөнки кеше үзенең бүгенге көне белән генә түгел, ә киләчәген кайгыртып яши. Гаиләсе, балалары, оныклары булган кешене бүгенге көннең уңайлыклары, өстенлекләре генә түгел, ә киләчәк тормышның да камил, төзек, дөрес булуы кызыксындыра. Шуңа да ул бу тормышны, җәмгыятьне яхшы якка үзгәртер өчен үз өлешен кертергә омтыла. Барыбыз да белә: канәгатьсезлек күрсәтеп, шөкер-сезлек белдереп кенә уңышка ирешеп булмый. Аллаһы Тәгалә Коръәндә: **«Аллаһы бер кавемгә [газап] яманлык [килүен] теләсә, аны бернәрсә дә кире бора алмас»,** – дигән.

«Әр-Рагъд / Күк күкрәү», 13:11

Адәм балаларының табигате шундый: алардан үзгәрешләр телисезме, дип сорасаң, алар, әйе, дип җавап кайтара. Ә үзгәрергә телисезме, дип сорасаң, эндәшүче юк, чөнки канәгатьсезлек белдереп, үзгәрешләр таләп итү җиңел, әмма җиң сызганып шул уңай якка үзгәрешләрне булдырырга тырышу бик авыр гамәл.

Галимнәр әйтүенчә, адәм баласы өчен иң авыр гамәл – ул рәхәтлеккә чыдый алмау. Тарихка күз салсак, кешеләр авыр сугыш елларында, узәккә үткән ачлык, ялангачлык вакытында да көчле авырлыкларны, сынауларны ерып чыга алган. Ә иң мөһиме авырлыклар белән күзгә-күз очрашса да, кешелек сыйфатларын югалтмаган: ярдәмгә мохтаҗ булганнарга булышып, булганына шөкер итеп яши белгән.

Менә бүгенге заманның төп бәласе шунда да инде, җәмәгать! Бүгенге көндә безгә – халыкка яшәешебез өчен булдырылган уңайлыкларны күрергә теләмәвебездә, ә һаман зарланып, нидер таләп итеп яшәвебездә. Өстебез бөтен, тамагыбыз тук булганда телебез шөкерне күбрәк әйтергә тиеш булса да, киресен эшләп яши бирәбез.


Илләребез, көннәребез тыныч, имин булып торганда, җитеш тормышта яшәгәндә һаман зарланып, ризасызлык белдереп тору мөселман кешесенең эше түгел. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр кеше иртән саусәламәт булып уянса һәм аның ашар ризыгы, кияр киеме булса, ул иң бай кеше инде», – дигән. Менә болар хакында фикер йөртсәк иде, җәмәгать!

Аллаһы Тәгалә һәрберебезнең күңеленә дә туры юлны – һидаять салып, бу тормышта җәмгыятебез өчен дә, кешеләр өчен дә файдалы булып яшәүләребезне насыйп итсен иде. Ил-көннәребезгә тынычлык, иминлек биреп, һәр яңа туган көнебезгә шөкер әйтеп, Аллаһының нигъмәтләрен күреп яши белсәк иде.

■ **Ленар Хамматов**



# Юныс галәйһиссәлам кыйссасы



Юныс галәйһиссәлам Ниневиядә – Ассирия дәүләтенең башкаласында Тигр елгасы яр буенда, хәзерге Мосул шәһәрендә туып үсә. Кавемдәшләре арасында ул ышанычлы, намуслы, әхлаклы һәм ярдәмчел булганга, олы хөрмәт казана. Әмма балык тарафыннан йотылуы белән, "Зөннүн" һәм "Сәхибел-Хөт" дигән исемнәр белән таныла.

30 яшендә Юныс галәйһиссәлам үзенең потларга табынучы халкына пәйгамбәр итеп җибәрелә. 33 ел дәвамында ул бертуктаусыз кавемдәшләренә дәгъват кыла, иманга килергә өнди, әмма ниневиялеләр аның сүзләренә колак салмый, көлә генә. Юныс галәйһиссәлам артыннан ике генә кеше иярә.

– Өч көн эчендә Раббым сезнең өскә җәза җибәрәчәк, – дип ул үз халкын Аллаһыдан алган хәбәр белән кисәтеп куя. – Бит-йөзләрегез саргаячак, соңыннан Яратучыдан җәза да киләчәк.

Шулай дип әйтеп, Юныс галәйһиссәлам җәзадан үзе дә куркып, туган шәһәрен ташлап, качарга ашыга. Әмма Аллаһыдан моңа рөхсәт алмый.

Ниневия халкын тиздән, Юныс галәйһиссәлам әйткәнчә, коточкыч дәһшәт камап ала: күк йөзен кара төтен каплый, ә кешеләрнең йөзләре саргая башлый. Алар пәйгамбәр әйткән сүзләрнең һәм якынлашып килә торган җәзаның хакыйкать булганына инана. Өсләренә һәлакәт килүен аңлап, ниневиялеләр Юныс галәйһиссәламне эзләргә тотына. Әмма юкка – ул шәһәрдә булмый инде.

## Ниневиялеләрнең бергәләп тәүбә кылулары

Аллаһы Тәгалә олы куркуда һәм өметсезлектә калган Ниневия кешеләренең йөрәкләренә тәүбә сала. Аның кисәтеп куелган җәзасы килеп җитүгә тагын ике көн бар иде, шуңа халык бергә җыелып Аллаһыдан котылу чарасын сорап, ялгышлыкта яшәүләре өчен гафу үтенеп тәүбә кылырга булалар. Шулай итәләр дә. Кавем тауга менеп Яратучының Барлыгына һәм Берлегенә, Аның расүле Юныс галәйһиссәламгә иман китерә һәм бер-берсенең дә үпкә-ачуларын гафу итәләр. Ирләр һәм хатын-кызлар, балалар һәм яшьләр – барысы бергә Аллаһыга ялваралар һәм күз яшьләренә йотылып ихластан Аннан гафу сорыйлар.

Аллаһы – Рәхимле һәм Гафү итүче. Ул башлыксыз калган кавемне дә кичерә – пәйгамбәр үз халкын ташлап китә, ә Раббыбыз аның тәүбәләрен кабул итә. Юныс галәйһиссәлам кавеме кешелек тарихында тәүбә иткән һәм һәлакәттән сакланып калган бердәнбер халык булып кала. Аллаһы Коръәндә болай дип әйтә:

**"[һәлакәткә дучар ителгән өммәтләр арасында] Юныс галәйһиссәламнең кавеменнән тыш, [газапны күргәннәреннән соң] иман китереп тә, иманнары аңа файда биргән бер [генә булса да] сала [халкы] булдымы соң? Алар [газап галәмәтләрен күргәннән соң] иман китергәч, Без алардан дөнья тормышында хурлык газабын алдык һәм аларны [Безгә мәгълүм] бервакытка кадәр [дөнья нигъмәтләреннән файдаландырдык".**

«Юныс», 10:98

Гөнаһлар афәткә, бәла-казаларга илтә, тәүбә исә коткарып кала. Мисал өчен, Аллаһы Расүле саллаллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай дип әйткән: "Раббысына истигъфар кылган бәндә җәзага тартылмаячагына ышана ала". Йөрәктән чыккан дога һәм ихлас күңелдән кылынган тәүбә теләсә нинди бәла-казадан коткарырга сәләтле. Әгәр дә афәт тулы бер кавемгә һөкүм итсә, гафу сорауны бөтен халык, җәмәгать белән ялварырга кирәк.

## Җирәбә Юныс галәйһиссәламгә чыга

Юныс галәйһиссәлам, үз халкын калдырып киткәч, диңгез ярына кадәр барып җитә дә, бер корабка утырып, диңгезгә чыга. Беркадәр ара барганнан соң, кораб кинәт туктый, көчле җил күтәрелә, давыл башлана. Көймә менә-менә батар кебек була. Корабны хәрәкәткә китерә алмаган диңгезчеләр, моны начар билге дип кабул итәләр һәм араларында җинаятьче бардыр дип уйлыйлар.

Диңгезчеләр корабта булган барлык кешене җыеп: «Сезнең арагызда хуҗасыннан качкан кол бар. Ул алга чыксын», – дип әйтәләр. Әмма берсе дә үз-үзен танытмый, шуңа күрә җирәбә салу турында карар кабул итеалә. Ул вакытта диңгезчеләрнең шундый йолаларсы була: кораб үз юлын дәвам итә алсын өчен, җирәбә төшкән кешене диңгезгә ташлыйлар.

Җирәбә уйнатыла. Һәм ул Юныс галәйһиссәламгә чыга.

"Мондый хөрмәтле кеше кол була алмый", – дип карар чыгарып, диңгезчеләр гафу үтенеп, янә җирәбә уйнаталар. Бу юлы да, өченче тапкырда да җирәбә барыбер Юныс галәйһиссәламгә чыга. Бу хакта Коръәндә болай дип әйтелә:

**"[Диңгезгә ыргытыласы кешене билгеләргә] Шобага тартты һәм оттырганнардан булды".**

«Саффәт / Сафта торучылар», 37:141

Өченче тапкыр уйнатылган җирәбәнең аңа төшүен күреп, Юныс галәйһиссәлам бу сынауның Аллаһыдан булуын аңлый һәм: «Мин – үз Хуҗамнан качкан колмын», – дип диңгезгә ташлана.

## Юныс галәйһиссәлам балык карынында

Юныс галәйһиссәлам тәвәккәлләп диңгезгә ташлана һәм Аллаһының рәхмәте белән аны шундук зур балык йота. Әлеге мизгелдә Аллаһы Тәгалә балыкка шундый мөмкинлек бирә ки, йоткан вакытта Юныс галәйһиссәламгә бернинди зыян килми, хәтта сөякләре дә сынмый. Балык, Юныс галәйһиссәламне йотып, диңгез төбенә төшеп югала.

**"[Диңгезгә ыргытылгач] Аны балык йотты. Ул [үзен] әрләгән бер кеше иде".**

«Саффәт / Сафта торучылар», 37:142

Шулай итеп, Юныс галәйһиссәлам бернинди зыян күрмичә һәм үз аңында булып балык карынында кала. Аның өчен барысы да көн кебек ачык иде: үз халкын рөхсәтсез калдырганга күрә бу вакыйгалар аңа иләһи кисәтү буларак җибәрелә.

*Дәвамы киләсе санда*

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан Республикасы мөфтие**

# Сынау ни сәбәпле килә?



Барча галәмнәрне барлыкка китереп, аларны тәрбия кылучы, безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин-мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп кылучы, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итүче Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң яхшы хәләл җефет, иң яхшы әти, иң яхшы дус, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шарифләребез булса иде! Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, нык сәламәтлек насыйп итсә иде! Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ, мөхтәрәм дин кардәшләрем!

Кеше тормышы шатлыклы һәм кайгылы вакыйгаларның алмашы белән үзенчәлекле. Галимнәр авырлыкларны берничә төрле сәбәп аркасында килә дип әйтәләр:

1. Гөнаһларга җәза итеп.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән:

«Мөселман кешесенә нәрсә генә килсә дә: арыганлык, борчылу, күңелсезлек, кайгы-хәсрәт, хәтта берәр үсемлекнең чәнечкесе кадалса да, Аллаһы Тәгалә аңа моның өчен берәр гөнаһысын ярлыкаячак».

2. Сынау рәвешендә.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Без, һичшиксез, сезне бераз – курку белән, бераз – ачлык белән һәм малларыгызга, җаннарыгызга, [бакча-басуларыгызга афәтләр җибәреп] уңышларыгызга бераз зыян китерү белән сынийбыз. [Расүлем!] [Сынауларга] Сабыр итүчеләрне [җәннәт белән] сөендер».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:155

Коръәни Кәримдә тагын болай дип тә килә:

**«Хөкемдарлык [кодрәт] фәрманында булган [Аллаһы] бөек, һәм Ул [һәрнәрсәгә көче җиткән] кодрәтле. Ул, сезнең кайсыгыз гамәлләренә күрә күркәмрәк булуын сынар өчен, үлемне һәм тереклекне яратты [сезнең кылачакларыгыз хакында әзәли гыйлемен уртага чыгарачак, соңыннан Үзенең гыйлеменә күрә түгел, кылганнарыгызга күрә әҗерләрегезне бирәчәк]. Ул – Бөек [Җиңелмәс], [гөнаһларны күпләп] Гафу итүче»;**

«Әл-Мүльк / Хөкемдарлык», 67:1-22

Шулай ук Аллаһы Тәгалә авыр сынаулардан соң җиңеллек киләчәген вәгъдә итә. Түбәндәге аять моның ачык дәлиле. Коръәни Кәримдә болай дип әйтелә:

**«Һичшиксез, [чиккән һәр] авырлыктан соң җиңеллек бар. Һичшиксез, авырлыктан соң җиңеллек бар».**

«Әл-Инширах / Ачылу», 94:4-5

Өмме Сәләмә радыяллаһу ганһә Пәйгамбәребез саллəллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Әгәр дә берәр кешегә кайгы-хәсрәт килсә: «Дөреслектә, без Аллаһы Тәгаләнеке һәм Аңа гына кире кайтабыз. Ий, Аллаһым, шушы кайгым сәбәпле миңа савап ирештер һәм миңа яхшырагын әйлә», – дип дога кылса, Аллаһы Тәгалә шушы кайгысы сәбәпле аңа әҗер-саваплар бирәчәк һәм бу кайгыга алмаш итеп нинди дә булса яхшылык җибәрәчәк», – дип әйткән сүзләрен риваять кылган.

3. Гомер дәверендә кылган гөнаһлардан пакьләнү өчен һ.б.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйткән:

**«Кылган [начар] нәрсәләрнең [бөтенесенең җәзасын Ахирәттә биргәнче] бер өлешен [дөньяда ук] аларга татытыр өчен, кешеләрнең куллары казанган [начар] нәрсәләр сәбәпле корыда һәм диңгездә бозыклык барлыкка килде. Бәлки, алар [гөнаһлардан] кайтырлар».**

«Әр-Рум / Румлылар», 30:41

Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллəллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дип әйткән:

«Кеше берәр төрле гөнаһ кылып: «Йә, Раббым, мин гөнаһлы гамәл башкардым. Мине ярлыка», – дип әйтер, Аллаһы Тәгалә аңа: «Минем колым аның гөнаһларын Белүче һәм ул гөнаһларны юкка чыгаручы Раббысы бар икәнлеген белә. Дөреслектә, Мин аның бу гөнаһын ярлыкадым», – дип җавап кайтарыр. Шуннан соң бу кеше кабаттан берәр төрле гөнаһ кылып: «Йә, Раббым, мин кабаттан гөнаһлы гамәл башкардым. Мине ярлыка», – дип әйтер, Аллаһы Тәгалә аңа: «Минем колым аның гөнаһларын Белүче һәм ул гөнаһларны юкка чыгаручы Раббысы бар икәнлеген белә. Дөреслектә, Мин аның бу гөнаһын ярлыкадым. Үзе теләгәнен башкарсын», – дип җавап кайтарыр. Шуннан соң Пәйгамбәребез бу сүзләрне өченче һәм дүртенче мәртәбә дә кабатлады».

Икенче бер хәдистә болай дип килә: "Биш вакыт намаз, һәр җомга намазы, һәр Рамазан аенда ураза тоту шул гамәлләр арасында кылынган кечкенә гөнаһларга (зур гөнаһлардан кала) ярлыкау булып торалар».

Бервакыт Пәйгамбәребез саллəллаһу галәйһи вә сәлләм авыр хәлле бер кеше янына килеп, аның хәле бөтенләй начар булганын күргәч: «Син догалар кылмыйсың мәллә, син Раббыңа ялвармыйсың мәллә?» – дип сорады. Теге кеше: «Әйе, кылам. Мин: «Раббым, Ахирәттә мине газаплый торган булсаң, җәзамны бу дөньяда ук бир», – дип сорыйм», – дип җавап кайтарган. Пәйгамбәребез саллəллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы барча кимчелекләрдән пакьтер. Дөреслектә, син моңа чыдый алмаячаксың! Нигә әле дога кылганда: «Йә, Аллаһым, бу дөньяда да, Ахирәттә дә безгә яхшы нәрсәләр бир, безне Ут газапларыннан сакла!» – дип әйтмәскә? Шуннан соң ул кеше Аллаһыга ялварып, шулай дип мөрәҗәгать итте, һәм Ул аны савыктырды.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, алда әйтеп үткәнебезчә, Аллаһы Тәгалә һәммәбезне дә сыный. Берәүләрне мал, икенчеләрен сәламәтлек, кайберләребезне балалар белән сыный. Бу сынаулар барысы да вакытлыча, алар үтә, авырлыклар да җиңеләя. Безгә Раббыбыз ул авырлыкларны җиңеләйтү юлларын да күрсәткән. Алар түбәндәгеләр:

1. Ярлыкау сорау, ягъни Аллаһы Тәгаләдән һәрдаим гөнаһларыбызны гафу итү, хата-кимчелекләребезне, ялгышларыбызны кичерүен сорау, тәүбә-истигъфар кылу тиешле.

2. Изге гамәлләр кылу (садакалар бирү, ярдәмгә мохтаҗларга ярдәм күрсәтү һ.б.).

3. Аллаһы Тәгаләгә дога кылып ялвару (ихласлык белән үз телебездә Аллаһы Тәгаләгә дога кылу).

Газиз кардәшләрем, тормыш сынаулары өметсезлек өчен сәбәп түгел, киресенчә, алар бездә сабырлык һәм максатчанлыкны үстерә. Тәүбә кылганда йөрәкләребезне сафландыра. Без шул вакытта Аллаһы Тәгаләнең янәшәдә булуын, һәм безгә бары тик игелек кенә теләгәнен тагы да катырак аңлый алабыз. Аллаһы Тәгалә безгә шушы тормыш авырлыклары аша Үзенә тагы да якынаерга насыйп әйләсә иде. Әмин!

■ **Марсель хәзрәт Мингалиев, МДНнең Дәгъват бүлеге белгече**

# Ана – бөек исем

**Исламда әни кешегә булган мөнәсәбәт – ул үзе бер дәреслек, яшәү күрсәтмәсе**



Ислам динендә әни кешегә зур игътибар бирелә. Изге Китабыбызда да, Расүлебез сөннәтендә дә ата-аналарга карата мәрхәмәтле, игътибарлы булуның мөһимлеге ассызыкланган. Әгәр кем дә булса, динебезне буярга, аның хөкемнәренә яла ягарга, дин катгый тыюлардан гына тора, дип әйтергә теләсә, әлегә мөһим мәсьәләне өйрәнсен, бу турыда күбрәк белергә омтылсын иде.

Ислам дине – тынычлык, игелек, мәрхәмәтлелек дине. Анда дорфалыкка, каты бәгырьлелеккә, әхлаксызлыкка урын юк. Әни кешене шул дәрәҗәдә хөрмәтләргә, бөекләргә кирәклеген без иң беренче чиратта Коръәннән һәм хәдисләрдән укып беләбез. “Җәннәт – әниләрнең аяк астында”, дип әйтелгән гыйбарә Расүлебезнең хәдисе икәнен белеп бетермәүчеләр дә бардыр. Аны кайберәүләр бары тик мәкаль яки тормыштан алынган сүзләр дип кенә кабул итәр.

Әмма Исламда әни кешегә булган мөнәсәбәт – ул үзе бер дәреслек, яшәү күрсәтмәсе. Боларны кечкенәдән аңлап, үзенә гомер бүләк иткән кешесен хөрмәтләп, олылап, әйткән изге нәсыйхәтләрен тыңлап үскән бала ялгыш юлга кереп китмәс, чөнки ана кеше беркайчан да баласына начарлык теләми, аны, балам тәүфикъсыз булсын, дип тәрбияләми. Үзе дә Ислам нуры белән яшәгән ана баласына туры юлны, һидаятьне күрсәтә алыр. Ә бала боларны аңлап үскән очракта итагатьле, инсафлы шәхес булып җитешер.

Әйе, бала әнисе алдында күпме генә тырышса да, аңа булган рәхмәтен әйтеп бетерә алмас. Берьюлы Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына бер сәхабә килеп, йә Аллаһының Расүле, минем анам картайды, өлешчә зиһенен югалтты. Мин аны үз кулларым белән ашатам, аңа су бирәм, аңа тәһарәт алырга ярдәм итәм, әниемне аркамда күтәреп йөрим. Мин аның алдында булган бурычымны үтәп бетердемме, дип сораган. Моңа җавап итеп Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

– Юк, син йөздән бер өлешен дә үтәмәдең. Ул син кечсез булганда сине карады, син үлмәсен өчен синә хезмәт итте. Син исә аның үлемен көтеп аңа хезмәт итәсең. Син берничек тә аңа бурычыңны түләп бетерә алмассың, әмма син игелекле гамәл кыласың, моны дәвам иттер, – дип әйткән.

## Бала күңеле – ак кәгазь

Әмма баланың әнисе алдында бурычы булу белән беррәттән, безнең – әниләрнең дә сабыйларыбыз алдында бурычларыбыз булганлыгын онытмасак иде. Ыгы-зыгы белән тулы, вакыт җитмәгән, бер көнебез бер сәгать кебек үткән мәшәкатьле дөньяда бу аеруча да мөһим.

Бала күңеле ак кәгазь кебек. Ул саф, пакь һәм гөнаһсыз җан иясе. Үсеп буйга җиткәч балаларыбызның нинди шәхес булып җитешүләре, ничек фикерләүләре безнең кечкенә вакытта аларга биргән тәрбиябездән, әйткән үгет-нәсыйхәтләребездән тора. Бүген күпләребез бала тәрбияләүне ашату-эчертү, киендерү, дөньяви гыйлем бирү, төрле түгәрәкләргә йөртүгә генә кайтарып калдырганда, сабыйларыбызны югары әхлаклы, көчле ихтыярлы итеп тәрбияләү мәсьәләсе икенче планга күчмиме икән?!

Җәлил хәзрәт үзенең вәгазьләрендә, китапларында Локман Хәкимнең әлеге гыйбарәсен китерүе дә юкка гына түгел. Ул: “Балага кечкенәдән Аллаһы Тәгалә турында сөйләмәсәң, картлыгыңны Аллаһы Тәгаләгә балаң турында сөйләп (зарланып) үткәрерсең”, – дип әйтә.

Әйе, берәү дә баланы алдына утыртып, кил мин сине тәрбиялим әле, дип әйтми. Бу мөмкин дә түгелдер. Тик шуны онытмасак иде: балаларыбызга тәрбия бирү үзебездән башлана. Балалар безнең көзгеләребез кебек. Алар безне тасвирлый. Без үзебезнең тотышыбыз, бу дөньяга, әйләнә-тирәбезгә, ата-аналарыбызга, туганнарыбызга, якыннарыбызга мөнәсәбәтебез белән балаларыбызга бу тормышны ничек алып барырга кирәк икәнлеген күрсәтәбез. Оясында ни күрсә, очканда шул булыр, дигән кебек, балаларыбызны олы тормыш юлына әзерлибез. Ә алар, үз чиратларында бу тәртипне үзләре төзегән ояларында кулланачак.


## Харамнан тыелу мөһим

Без күп әйберләрне белеп тә бетермәскә мөмкин. Әмма шулай да иң гади һәм мөһим булган тәртипләр бар. Ул – балаларыбызга хәләл ризыклар гына ашату. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: “Балаларыгызның тәнен харам ризыктан җыйсагыз, көче ныгыгач, үзегезгә каршы борылыр”, – дигән. Төрле зыянлы, хәләл булмаган кушылмалардан торган тәм-томнар балаларның әле ныгымаган организмына зарар сала. Кызганычка, бу аларның тәртипләре бозылуга, игътибарсыз, таркау булып үсүләренә дә сәбәп булырга мөмкин. Кызганычка, күпләребез моңа зур әһәмият бирми. Хәләл ашауны, харамнан тыюлуны дингә генә кайтарып калдыра. Әмма харамнан ерагаю, иң беренче чиратта, безнең үзебезнең бәхетебез, иминлегебез өчен мөһим.

Ана бөек исем. Аллаһы Тәгалә әни кешене баласы, гаиләсе алдында шундый зур вазифалары булганга күрә бөекләгән дә инде. Безнең өчен тырышлык куйган әниләребезне хөрмәтләп, олылап яшәп, балаларыбызны да безне олылый алырлык итеп тәрбияли алсак иде.

■ **Айсылу Юлдашева**

# Нәзарәттә Туган тел елына беренчел нәтиҗәләр чыгарылды




12 нче ноябрьдә Лаеш районы “Волга” яшьләр үзәге базасында ТР мөселманнары Диния нәзарәте Пленумының күчмә утырышы уздырылды. Анда Татарстан Диния нәзарәте тарафыннан игълан ителгән Туган тел елына беренчел нәтиҗәләр чыгарылды.

Утырышта Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, аның урынбасарлары, ТР баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, шулай ук бөтен республикадан имам-мөхтәсибләр һәм мөфтият эшчәнлегенең барлык юнәлешләре һәм оешмалары җитәкчеләре катнашты. Җыелышның мәртәбәле кунагы булып ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Президенты каршындагы татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов, БИА ректоры Данияр Абдрахманов торды.

Татарстан мөселманнары башлыгы Камил хәзрәт Сәмигуллин, пленумда катнашучыларны сәламләп, үз чыгышында тыңлаучыларның игътибарын көн кадагында торган мәсьәләләргә җәлеп итте. Аерым алганда, ул Татарстан мөфтияте тарафыннан быел игълан ителгән Туган тел елы кысаларында башкарылган эшчәнлеккә беренчел нәтиҗәләр чыгарды.

– Иң беренчесе: узган елның ахырында бастырылган “Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә” хезмәте 2020 елда бөтен татар җәмәгатьчелегендә танылды, һәм китап буларак кына түгел, ә башка рәвешләрдә дә дөнья күрде, – диде Камил хәзрәт һәм әлеге басма белән бүген республикадагы һәр мәчет тәэмин ителгәнлеге турында хәбәр итте. Сүз уңаеннан, китаплар татарлар күпләп яшәгән Рәсәй төбәкләрендә бушлай тарату өчен һәм милләттәшләрдә милли үзаң дәрәҗәсен күтәрү өчен нәшер ителде. Шуңа күрә махсус тираж булып бастырылган китап туган телне сакларга кирәк дигән мөрәҗәгатьтән башлана. Китап Иваново, Мәскәү, Санкт-Петербург, Башкортостан татарларына озатылды һәм бу эш дәвам итә.

Мөфти үз чыгышында шушы хезмәтнең быел аудиоверсиясе чыгуын да искә алды. 40 сәгатьлек аудиоязма “Азан” радиосында танылган алып баручы Илдар Кыямов тавышы белән яздырылды. Башта бу язма сатуда гына булса, хәзер инде аны “Азан” радиосы сайтыннан телефонга бушлай күчереп алып тыңларга була. Моннан тыш, шушы ук аудиоязма Төркиядә җитештерелә торган Коръән каләменә кертелде. Мөселманнар арасында зур популярлык казанган әлеге гаджет каләм рәвешендә эшләнгән һәм махсус Коръән басмасы белән бер комплектта килә. Каләм аятьләрне номер буенча танып ала һәм аның гарәпчә әйтелешен, шулай ук башка төрле телләргә тәрҗемәсен әйтеп бирә. Шулай итеп, бу җайланманың программасында хәзер, дөньяның башка милли телләре белән беррәттән, Коръәннең татарчага тәрҗемәсе дә урнаштырылды.

Камил хәзрәт Сәмигуллин хәбәр иткәнчә, Нәзарәт тарафыннан игълан ителгән Туган тел елы ахырына кадәр Коръәннең мәгънәви тәрҗемәләренең текстлары һәм аудиосы мобиль кушымта буларак та эшли башлаячак. Ягъни теләгән һәркем алардан бушлай файдалана алачак. “Җәмәгать! Бу хезмәт – Аллаһы ризалыгы өчен эшләнде һәм халык арасында да ул бушлай таратылачак”, - дип ассызыклады мөфти хәзрәтләре.

Туган тел елының тагын бер мөһим казанышы итеп Камил хәзрәт Татарстанның 100 мәчете каршында татар теле курслары оештырылуын атады. Бүгенге көндә аларга 1225 кеше йөри, ягъни уртача 10-12 кешелек төркемнәр формалашкан.

Мөфти шулай ук үз чыгышында 2020 ел ахырына кадәр татар телендә эшли торган тагын бер яңа проект – онлайн-мәдрәсә ачылырга тиешлеген хәбәр итте. “Дин нигезләрен өйдән торып, интернет аша өйрәнеп булачак. Проектның бөтен контенты әзер. Ул 100% татар телендә”, – диде Камил хәзрәт Сәмигуллин.

Сүзен дәвам итеп, мөфти хәзрәт Татарстан мөфтиятенең тагын бер мөһим эш юнәлеше булып яшьләр белән эшләү икәнлеген билгеләп үтте һәм перспективалы “Яшь килен” проекты эшли башлавын хәбәр итте. «Яшь килен» татар кызлары арасында гаилә кыйммәтләрен ныгыту максатыннан гамәлгә ашырыла, шәригать һәм татар милли гореф-гадәтләр күзлегеннән чыгып хатын-кызларны никахта яшәргә өйрәтә. Биредә хатын һәм ирнең бурычлары һәм хокуклары, хатын-кыз һәм ир-ат психологиясе, бала тәрбияләү кебек мәсьәләләр турында сөйләнә. Аерым дәресләр булачак. Алар хәзерге яшь киленнәргә татар милли традицияләре – бәби чәе, бишек җыры, кыз озату, милли ашлар, бала карау, кунакларны каршылау кебек темаларга кагыла”, – дип, Камил хәзрәт хатын-кызның – милләтнең йөзе булуын, аның дини, милли һәм кыйммәтләрен саклап калудагы роле бәяләп бетергесез икәнлеген, милләттәшләребезне һәм дин кардәшләрне хатын-кыз тәрбияләвен ассызыклады. Проектка Казан мөслимәләре генә түгел, Мәскәү, Уфа, Пенза, Чиләбе кебек төбәкләрдә яшәүче татар кызлары да кушылды.

Камил хәзрәт Сәмигуллин, имам-мөхтәсибләргә мөрәҗәгать итеп, халыкта татарлыкны саклап калуның дин әһелләре алдында да торган бурыч икәнлеген ассызыклап үтте. “Чөнки милләттәшләребез татар булудан туктаса, үзен мөселман дип тә танымаячак, мәчетләргә дә юлны онытачак. Шуңа күрә мәчетләрдә тулы мәгънәдә татар телле мохит булдырырга һәм сакларга кирәк. Халык белән аралашу, җомгаларны уздыру, төрле чараларны татар телендә алып барырга онытмагыз. Гамәлдә сез бу эшне болай да алып барасыз: дин дәресләре, яшьләр өчен тәрбияви чаралар, балаларга җәйге һәм кышкы каникуллар оештырасыз, сабантуйлар, иҗади бәйгеләр уздырасыз. Мисал өчен, быел мәчетләр 2500 бала өчен кышкы каникуллар оештырган. Зур рәхмәт сезгә! Шушы эшне дәвам итәргә кирәк”, – дип мөрәҗәгать итте мөфти хәзрәтләре һәм киләсе елның Татарстан Президенты тарафыннан Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы итеп игълан ителгәнен искә алды.

ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Президенты каршындагы татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов шушы һәм туган телне һәм милли үзенчәлекләрне саклау өлкәсендәге Нәзарәтнең башка эшчәнлеген югары бәяләде һәм башлангычларны тормышка ашыруда ярдәм кулын сузарга әзерлеген әйтте.


Пленумда башка мәсьәләләр дә каралды.

■ dumrt.ru сайтыннан

# Һәр эшнең башы – “Бисмилләһ”



Коръән сүрәләренең барысы да, бары бер сүрәдән кала, “Бисмилләһ” сүзе белән башлана. Коръәнне “Бисмилләһ” сүзе белән укый башлаган кебек үк, тормышыбыздагы һәр эшне дә әлеге сүз белән башлап җибәрәбез. “Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим” яки кыскача “Бисмилләһ” – “Рәхимле һәм Рәхмәтле Аллаһы исеме белән” дигәнне аңлата. Әгәр берәр эш башласак, һичшиксез, аны безгә ярдәм итүче Аллаһының исемен искә алып башкарабыз. Мөселман кешесе нәрсә генә эшләсә дә, аның телендә “Бисмилләһ” сүзе. Кибетләр “Бисмилләһ” сүзе белән ачыла, юлга “Бисмилләһ” белән чыгабыз. “Бисмилләһ” сүзе мөселман гореф-гадәтләренең иң мөһим символы.



# Зәкят түләмәү

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**“Алтын һәм көмеш җыйган һәм аларны Аллаһы юлында [зәкят биреп] сарыф итмәгән кешеләрне тилмерткеч бер газап белән «сөендер». Бу [Аллаһы юлында сарыф ителмәгән маллары] җәһәннәм утында кыздырылган һәм шулар белән [зәкят бирмәүчеләрнең, фәкыйрьләрне күргән чакта чырайлары сытылучыларның] маңгайлары, [мохтаҗларның сорауларына читкә борылучыларның] янтыклары һәм аркалары тамгаланган Көнне: «Бу үзегез өчен җыйган нәрсәләрегез, инде җыйган нәрсәләрегезне татыгыз!» [диеләчәк]”.**

«Әт-Тәүбә», 9:34-35

Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Дөя, сыер яки сарык иясе булган берәр кеше аларга карата тиешле мөгамәләдә булмаса, Кыямәт көнендә тигез һәм иркен урынга утыртылачак. Алар (ул хайваннар) бу кешене тояклары белән таптаячаклар, мөгезләре белән сөзәчәкләр һәм тешләячәкләр. Шулай ук көтүе белән дөяләр дә аның өстеннән йөриячәк. Аның өстеннән дөяләрнең соңгысы узгач, кабаттан беренче дөя кайтарылыр. Һәм бу хәл дәвамлыгы 50 мең ел булган Кыямәт көне беткәнче дәвам итәр. Шуннан соң аңа йә җәннәткә, йә җәһәннәмгә юл күрсәтеләчәк” (Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан; хәдиснең бер өлеше).

«Әгәр хәзинәләре булган кеше аларга карата тиешлесен үтәмәсә (зәкят чыгармаса, садака итеп бирмәсә (ред.), Кыямәт көнендә бу байлыклар аның алдында бик зур елан булып киләчәк” (Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан).

Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе зәкят түләүдән качып йөрүчеләр белән көрәшә торган булган һәм болай дигән:

«Аллаһы Расүленә биргән кебек, ул кешеләр миңа бер кәҗә генә булса да бирергә теләмәсәләр, мин алар белән шуның аркасында да көрәшермен” (Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан).

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**“Аллаһының фазылыннан бирелгән нәрсәдә [зәкят һәм садакага каршы булып] саранлык күрсәтүчеләр моны үзләре өчен яхшырак дип санамасын. Киресенчә, бу алар өчен начаррак. Саранланып кызганган нәрсәләре Кыямәт көнендә [елан кебек] аларның муеннарына уралачак. Күкләрнең һәм җирнең мирасы – Аллаһыныкы гына. Аллаһы сезнең ни кылганнарыгыздан хәбәрдар”.**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:180

Пәйгамбәребез мондый очракларда болай дип әйтә торган булган: «Зәкят бирүдән баш тарткан кешеләрдән зәкятне дә, малларының яртысын да алырмын. Бу – Аллаһы Тәгаләнең хокукларының берсе».

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең түбәндәге сүзләрен ишеткән: «Җәһәннәмгә беренче булып түбәндәге өч төркем керәчәк:

– үз халкына золымлык кылган хөкемдар;

– милкенә карата тиешлесен үтәмәгән (зәкятен чыгармаган (ред.) кеше;

– тәкәббер фәкыйрь».

# Ата-ананы хөрмәтләмәү

**“Раббың сезгә Үзеннән башкаларга табынмаска, ата-анага игелек [кылырга] әмер итте. [Ий кеше!] Аларның икесеннән берсе яки икесе дә синең яныңда картлыкка ирешсә, аларга [канәгатьсезлек белдереп]: «Уф!» – дип тә әйтмә. [Сүз-гамәлләре сиңа ошамаса да] Аларга кычкырма, күркәм сүз әйт. Мәрхәмәтлектән алар алдында тыйнаклык канатын җәй һәм [кяфер булсалар да, һидаятькә ирешүләрен Аллаһыдан сорап]: «Ий Раббым! [Минем фани мәрхәмәтем нәрсә генә ул?] Алар кечкенә чагымда мине [зур бер шәфкать белән] үстергәннәре кебек, Син дә аларга [бакый рәхмәтең белән] мәрхәмәт ит», – дип әйт”.**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:23-24

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм җиде зур гөнаһларны санаганда, алар арасында ата-ананы хөрмәтләмәүне дә искә алды».

Шулай ук Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте – атаның рәхмәтендә, ә Аның ачуы – атаның ачуында ята», – дип әйтә.

Шулай ук Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм мондый хәдис әйтеп калдырган: «Әтиеңә карата булган яхшы мөнәсәбәтең җәннәткә иң яхшы ишек аша керергә сәбәпче булачак. Аның (әтиеңнең) хокукларын үтәргә тырышып, бу ишек аша узуың яки аларны үтәмичә, хакларын кысрыклап, аңа (шул ишеккә (ред.) юлны югалтуың хәзер сиңа гына бәйле».

Шулай ук ул: «Җәннәт – әниләрнең аяк астында», – дип әйткән.

Берьюлы пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына бер сәхабә килеп, җиһадта катнашырга рөхсәт сораган. Расүлебез аннан:

– Синең әти-әниләрең исәнме? – дигән.

Теге сәхабә:

– Әйе, – дип җавап биргән.

Шуннан соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аларны тәрбияләү синең җиһадың булсын”, – дигән (Бохари, Китап-Әл-Җиһад, 3004; Мөслим Китап-Әл-Бирр, 2549; Тирмизи 1671).

Бервакыт Расүлебездән, кемгә карата яхшы мөнәсәбәттә булырга кирәк, дип сораганнар. Ул: «Әнигә, әтигә, кыз туганыңа, ир туганыңа, синең өчен иң якын булган кешегә һәм туганлык буенча чираттагы иң якын кардәшеңә», – дип җавап биргән (Мөслим Китап-Әл-Бирр, 2548; Ән-Нәсаи, 5/61; Ибне Мәҗә, 3658).

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең түбәндәге сүзләре риваять ителә:

«Түбәндәге кешеләр җәннәткә кермәячәк: ата-анасын хөрмәтләмәүче, кылган яхшылыгы белән шелтәләүче, исерек кеше һәм сихергә ышанучы” (Ән-Нәсаи, Китап-Әл-Әшрибе, 8/318; Әхмәд бине Хәнбәл 3/314).

Габдулла бине Гомәр радыяллаһу ганһе, Расүлебез янына бер кеше килеп, йә, Аллаһының Расүле, нинди гөнаһлар иң зурлардан санала, дип сораганын хәбәр итә.

Пәйгамбәребез:

– Аллаһыга ширек кылу, – дип җавап биргән.

Теге кеше:

– Тагын нинди гөнаһ? – дип сораган.

Пәйгамбәребез:

– Ата-ананы тыңламау, – дигән.

Сорау бирүче, болардан соң нинди гөнаһлар, дигән.

Расүли Әкрам:

– Ялган ант, – дип җавап кайтарган.

Габдулла бине Гомәр радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребезнең түбәндәге сүзләрен китерә:

«Ата-анасын олыламаучы һәм тәкъдирне кире кагучы җәннәткә кермәс”

(Әхмәд бине Хәнбәл, 2/441).

Бер кеше Расүлебездән: «Йә Аллаһы Расүле! Әгәр мин биш вакыт намаз укысам, Рамазан аенда ураза тотсам, зәкят түләсәм, Аллаһы йортын – Бәйтуллаһны зиярат кылсам, син миңа нәрсә эшләргә әмер итәрсең?» – дип сораган. Пәйгамбәребез: «Әлеге шартларны үтәүче һәм ата-анасын хөрмәтләүче – пәйгамбәрләр, әүлияләр һәм шәһитләр белән булачак», – дип җавап биргән.

Аллаһының Расүле болай дигән:

«Аллаһы Тәгалә гөнаһлар өчен җәза бирүне Кыямәт көненә хәтле кичектерер. Әмма ата-ананы хөрмәтләмәгән өчен җәзаны тиз арада, ашыгыч рәвештә бирәдер” (Хәким, Мүстәдрәк, Китап-Әл-Бирр вәс-Силә, 4/156).

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе: «Бер генә бала да атасына булган рәхмәтен җиткереп бетерә алмый. Бары тик әгәр ул аны әсирлектә табып, коткарса гына рәхмәтен әйтеп бетергән булып санала», – дип әйткән (Мөслим, Китап-Әл-Гыйтк, 1510; Әбү Давыд, Китап-Әл-Әдәп, 5137; Тирмизи, Китап-Әл-Бирр Вәс-Силә, 1907).

Расүлебез: «Ата-анасын олыламаучыны Аллаһы ләгънәт кылсын”, – дигән (Хәким, Мүстәдрәк, 4/153).

Шулай ук Пәйгамбәребез: «Апаң (әниеңнең кыз туганы) синең өчен әниең кебек», – дигән (Тирмизи, Китап-Әл-Бирр вәс-Силә, 1905).

Кәгъб болай дигән:

«Аллаһы белән ант итәм: әгәр кеше ата-анасына каршы барса, Аллаһы аны юкка чыгарырга һәм җәзага тартырга ашыгыр. Ә ата-анасына яхшы мөнәсәбәттә булучының Аллаһы гомерен озынайтыр һәм яхшы гамәлләрен арттырыр».

■ **Имам Әз-Зәһәбинең “Әл-Кәбаир” китабыннан**

# Рус императорларын Ислам белән таныштырган беренче кеше

XVIII гасыр башына Рәсәй империясе Исламга аеруча да кызыксыну белдерә башлый. Моңа Петр I нең мөселман илләре белән сәүдә элемтәләрен җайларга теләве дә, ислам динен тотучы гражданнарны аңларга тырышуы да, шулай ук Рәсәйнең Госманлы империясе һәм Иран белән сугышлар барлыкка килүгә китергән, көньяк чикләрендәге геополитик активлыгы да йогынты ясый.

Югары катлам кешеләрен Ислам дине белән таныштыруда Рәсәйнең һәм Молдавиянең танылган галиме, Петр I заманында дәүләт эшлеклесе һәм дипломат Дмитрий Константин улы Кантимер (1673-1723) зур роль уйный. Ул Молдавиянең хөкүмәт җитәкчесе Константин Кантимер улы, ә аның бабасы – татар морзасы Кантимер, Нугай Урдасына нигез салучы Алтын Урда башлыгы Идегәй нәселеннән була.

Константин Кантимер идарә иткән елларда Молдавия Госманлы империясенә вассал рәвештә, ягъни икътисадый һәм сәяси яктан бәйле иде. Ул вакытлардагы традицияләр буенча, 15 яшьлек Дмитрийне Стамбулга тоткын итеп җибәрәләр. 1693 елда ул кыска вакытка Молдавия җитәкчесе булып ала, әмма озакламыйча вазифасыннан алына һәм яңадан Стамбулга җибәрелә. Госманлы башкаласында булган вакытта Дмитрий төрек, гарәп һәм фарсы телләрен өйрәнә. Ул үз заманының бик укымышлы кешесе була. Санап үтелгән көнчыгыш телләреннән тыш, ул молдаван, латин, рус, грек, итальян һәм француз телләрен дә белгән. Үз вакытында хәтта Петербургтагы Фәннәр Академиясе президенты вазифасына кандидат буларак та каралган.

Госманлы империясе белән Рәсәй арасында барган сугыш вакытында, 1710 елда Дмитрий Кантимер Молдавия господаре (Молдавия җитәкчесе титулы) була. Әмма үз илен Госманлыларга бәйлелектән азат итәргә теләп, Петр I белән союз төзи һәм руслар ягына күчә. Моннан соң ул Петербургта, Мәскәүдә һәм Дмитровкадагы утарында (хәзерге Орловка өлкәсе) яши һәм эшли.

1719 елда Дмитрий Кантимер тарафыннан “Книга Систима, или Состояние мухаммеданския религии” (“Sistema de religione et statu Imperii Turcici”), шулай ук «Система турецкого вероисповедания» исеме белән танылган китап языла. Аның нигезенә Кантимер “Коран” (“Curanus”) китабының латин текстын куллана. 1722 елда китап Иван Ильин тарафыннан латин теленнән рус теленә тәрҗемә ителә. 1722 елның 18 июлендә Петр I дини эшләр белән идарә итә торган төп орган – Синодка аны кичектермичә басмага куярга һәм Каспийдагы армиягә җибәрергә куша. 1722 елның 22 декабрендә китап нәшер ителә. Бу – императорның түземсезлек белән китапның басылуын көткәнен күрсәтә.


Бу китап Ислам турындагы бар мәгълүматны үз эченә алган рус телендәге беренче хезмәт. Дмитрий Кантимер аны көнбатыш Аурупа һәм рус чыганакларына гына түгел, ә мөселман чыганакларына һәм шәхси күзәтүләренә дә таянып яза. Кантимер үзенең китабында Исламны гомуми үзенчәлекләрдә аңлата, әмма күп вакыт Стамбулда яшәгәнгә күрә, төрекләр арасында таралган Исламның үзенчәлекләренә зур игътибар бирә. Мәсәлән, Дмитрий Кантимер Изге Коръән Китабы турында түбәндәгеләрне яза:

“Куран сложен есть на Арапском языке, изряднейшим штилем, и по болшеи части рифмическим, речию Арапскою, так глубокою, что не токмо подражать того, всячески несть мощно, но и ко истолкованию зело труден есть, паче же рещи, весма не объятен. Аще сам Муфти, или кто от ученнеиших Турков, и в Арапском языке искусснеишии, вопрошен бы был, может ли хотя един каковыи стих, или Сентенцию Курана, по словам и по разуму купно, и совершенно разумети? по правде ответствуют, что никакоже разумеют, но отсылают к древнеишым Курана толкователем, и в них слова, или Сентенции, о которых сумнение есть, искать повелевают”.


Рәсәйнең югары җәмәгатьчелеге китапны төрлечә кабул итә. Кайберәүләр, автор Ислам турында артык яхшы фикер белдерә дип саный. Гәрчә Кантимер христиан динендә була һәм исламга христиан дине күзлегеннән карап язган була. Әмма үзенең күп әйберләргә аек акыллы карашы белән, бу хезмәт шул чорның башка христиан хезмәтләреннән аерылып тора. Биредә Кантимер үзен Ислам белгече, шул исәптән Коръән, суфичылык, гарәп, фарсы, госманлы телләре белгече буларак күрсәтә алган.

Һичшиксез, Кантимерның китабы үз вакыты өчен алга киткән хезмәт була. Көнбатыш Аурупада “Книги Систима” кебек хезмәт 150 ел үткәч кенә языла. Ул И. Гольдциерның немец телендә язылган “Магометанские исследования” (Halle, 1889–1890) китабы була.

**■ Мөхсин Нурулла язмасы, islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә**




*Царицынода Дмитрий Кантемирга куелган һәйкәл*


КНIГА
СVСТIМА
ИЛИ
СОСТОЯНIЕ
мухаммеданскiя религiи.
НАПЕЧАТАСЯ ПОВЕЛѢНIЕМЪ ЕГО ВЕЛIЧЕСТВА
ПЕТРА ВЕЛIКАГО
IМПЕРАТОРА И САМОДЕРЖЦА ВСЕРОССIИСКАГО.
ВЪ ТVПОГРАФIИ ЦАРСТВУЮЩАГО
САНКТЪПIТЕРБУРХА.
Лѣта 1722, Декабря въ 22 день.

*“Книги Систима”ның беренче бите*



# Урынның, вазифаның һәм тәхетнең кыйммәте

Бер падишаһның бик каты итеп эче авырта башлаган. Бу аны шулхәтле газапка салган, хәтта ул урын өстенә калган. Түзәр чамасы калмаган падишаһ болай дип әйткән: "Кем дә булса мине бу чирдән коткарса, мин аңа бөтен байлыгымны бирәм һәм үземнең тәхетемне тапшырам".

Аллаһының дусларыннан булган берәү, падишаһның авыр хәле турында белеп, аның янына килгән һәм эчен сыпыра башлаган. Моны эшли башлагач, бүлмәгә начар ис таралган һәм падишаһ терелеп, аякка баскан.

Шуннан соң ул бу кешегә:

– Тәхетемә утыр, мин сүз биргән идем һәм синең өчен хакимлегемнән баш тартам, – дип әйткән.

Аллаһының дусты:

– Мин кыйммәте эчәклекләр һавасына тиң булган әйбергә мохтаҗ түгелмен. Әмма син моннан гыйбрәт ал: сине шундый түбән дәрәҗәдәге кыйммәткә ия булган әйберләр алдады, – дип җавап биргән.

### Нәсыйхәт:

Кешең иң зур байлыгы – ул аның сәламәтлеге. Аның кадерен белергә һәм аны сакларга кирәк. Бу хакыйкатьне бәян итеп, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: "Кеше тарафыннан кадере булмаган ике нигъмәт бар. Берсе – сәламәтлек, икенчесе – буш вакыт"(Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан).

# Сындырып булмый торган бәйләм

Үлем түшәгендә ятучы бер хикмәт иясе улларын җыеп алган да:

– Һәрберегез берәр чыбык алсын, – дип әйткән.

Уллары әтиләре әйткәнчә эшләгән. Хикмәт иясе барлык чыбыкларны бер бәйләмгә җыйган да, бу чыбыкны сындырыгыз, дигән.

Уллары ничек кенә тырышса да, бәйләмне сындыра алмаган. Аннары хикмәт иясе бәйләмне сүтеп, һәрберсенә берәр чыбык өләшеп чыккан. Бу юлы уллары чыбыкны бер авырлыксыз сындырганнар.

Шуңа күрә хикмәт иясе:

– Миннән соң сез бу бәйләмнең чыбыклары кебек булачаксыз. Сез бергә булганда сезне беркем дә җиңә алмаячак. Әмма аерым-аерым булсагыз, сезнең дошманнарыгыз сезне җиңәчәк.

### Нәсыйхәт:

Җәмәгать белән бергә булган кешеләргә Аллаһы ярдәм итә. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйткән:

**"Барыгыз бергә Аллаһының арканына [Китабына һәм диненә] ныклап ябышыгыз..."**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:103

**"...Аллаһыга һәм Аның Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә итагать итегез. [Бәдергә чыгу кебек фикер каршылыкларына төшмичә] Сүз көрәштермәгез, соңыннан куркуга төшәрсез..."**

«Әл-Әнфәл / Табышлар», 8:46

# Сөт белән бирелә торган холык

Берьюлы шәех Әбү Мөхәммәд Әл-Җүвәйни рахимәһуллаһи өенә кайткач, улы Әбел Мүәләне әнисе түгел, ә чит хатын-кыз имезеп утырганын күрә. Ул тиз арада улын аның күкрәгеннән аерып ала да башын йөзтүбән каратып, баланың корсагын сыйпый һәм аннары бармагын аның авызына тыга. Ул бала косып, эчкән бөтен сөтен чыгарып бетергәнче шулай эшләвен дәвам итә. Ә үзе: "Башка хатынның сөте аркасында холыкны бозганчы, үлем хәерлерәк", – дип әйтә.

Еллар узгач, әлеге малай үсеп җитеп имам һәм зур галим була. Бәхәсләр вакытында төртелеп калганда ул: "Бу тотлыгуларның сәбәбе: теге хатынның ашказанымда калган сөте", – дип әйтә торган була.

### Нәсыйхәт:

Әлеге кыйссаны бәян итүче Исмәгыйль Хаккый Бурсави куддисаллаһу сирруһу мондый аңлатма бирә: "Әлеге кыйссадан шуны билгеле: күкрәк сөтен имүче бала әлеге хатын-кыз холкының яхшы һәм яман якларын үзләштерә. Ашый торган итнең тәэсире дә шулай ук зур икәнен исәптә тотарга кирәк".

# Сәфәргә чыгучы кеше

Зәед бине Сабит радыяллаһу ганһе бер монафикъ (икейөзле) кеше белән Мәккәдән Таиф шәһәренә сәфәргә чыккан. Әмма ул бу кешенең икейөзле булуын белмәгән. Юлда алар бер җимерек йортка кереп кунарга тукталганнар.

Күпмедер вакыт үткәннән соң монафикъ уянып, Зәеднең кулларын бәйләгән дә аны үтерергә теләгән. Шулвакытта Зәед уянып Аллаһыга дога кылган: "Йә Рәхимле Аллаһы! Миңа ярдәм ит". Моннан соң монафикъ тыштан тавыш ишеткән: кайгы булсын сиңа, үтермә аны. Монафикъ тышка чыккан, әмма берәүне дә күрмәгәч, кире әйләнеп кергән. Һәм кабат шул ук тавышны ишеткән. Бу хәл өч тапкыр кабатланган.

Болардан соң атлы кеше пәйда булып, монафикъны үтергән. Аннары Зәедне азат итеп болай дип әйткән: "Мин Җәбраил. Син Аллаһыга дога кылгач, мин дүртенче кат күктә идем. Аллаһы миңа, Минем колыма ярдәм ит һәм аны коткар, дип әйтте".

### Нәсыйхәт:

Сәфәргә җыенучы кеше үзе белән иптәш алырга тиеш, әмма иминлек өчен бу кешенең кемлеген яхшылап белү мөһим.

Аллаһы Тәгалә авыр хәлдә калган колын ярдәменнән ташламый. Һәм көтмәгән җирдән Үзенең ярдәмен бирә, чөнки һәрнәрсә Аңа буйсынган.

«Рухуль Бәйан» китабыннан

# Ислам тарихында эз калдырган мөслимәләр

“Берәү Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән үз туганнары арасында кайсының аңа күбрәк хакы барлыгы хакында сораган. Пәйгамбәребез салләлаһу галәйһи вә сәлләм: “Әниең”, – дип җавап биргән. “Ә тагын кем?” – дип сорагач та, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шул ук җавабын кабатлаган. Теге кеше янә үз соравын кабатлап сораган. Аллаһының Расүле шулай ук җавап кайтарган. “Алай да, аннан соң кем?” – дип сораган бу кеше. Дүртенче тапкыр сорагач кына Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: “Ә менә хәзер синең әтиең”, – дип җавап кайтарган.

Ислам диненең үсешендә, милләтнең әхлакый сыйфатларын камилләштерүдә, балаларны дини рухта тәрбияләүдә хатын-кызларның керткән өлешен танымаган берәү дә табылмас, мөгаен. Мөслимәләр һәрвакыт үзләренең ныклы иманнары, зирәклекләре, әдәплелекләре белән башкалардан бик нык аерылып торганнар.

Исламга кадәр булган дәвердә гарәп илендә хатын-кызлар теләсә нинди хокуклардан мәхрүм булганнар. Төп вазифалары балалар тудыру, ирен һәм өй эшләрен караудан гыйбарәт булган. Аларның берниндисүз, сайлау ирегедә булмаган. Бары тик Ислам дине килгәч кенә хатын-кызларга күпмедер дәрәҗәдә хокуклар бирелеп, алар күркәм нәсел дәвамчылары тәрбияләүгә генә түгел, ә өммәтебезнең үсешенә, Ислам динен дөнья буйлап таратуга үзләренең барлык көч-куәтләрен түктеләр.

Мисалга пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллау галәйһи вә сәлләмнең хатыны – **Хәдичә бинте Хөвәйлид радыяллаһу ганһә**не генә алыйк. Ул сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән яшь ягыннан шактый олы булып, үзенең зирәк акылы, эшкуарлык өлкәсендә шактый осталыгы белән аерылып торган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, бигрәк тә пәйгамбәрлегенең беренче елларында бик зур ярдәм иткән һәм нык терәк булган. Ислам диненең хатын-кызлар арасында таралуына зур этәргеч ясаган, шул рәвешле, беренче мөслимә дәрәҗәсенә лаек булган, ягъни хатын-кызлардан иң беренче булып иман китергән.

Имам Мөслимнең сахих хәдисләр җыентыгында түбәндәге хәдис китерелгән: пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: “Бөек һәм Кодрәтле Аллаһы Тәгалә бу дөньяда миңа аннан да яхшырак берәүне дә бирмәде. Башкалар миннән йөз чөергәндә, кире какканда, ул мине кабул итте; кешеләр миннән шикләнгәндә, ул миңа ихластан ышанды; кешеләр мине бөтен барлыгымнан мәхрүм иткәндә, ул барлык байлыгы, малыннан минем белән бүлеште; Аллаһы Тәгалә миңа бары тик аннан гына балалар бүләк итте”.

Ислам дине таралуда үз эзен калдырган хатын-кызлар арасында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Хәдичә радыяллаһу ганһәдән туган кызы **Фатыйма Әз-Зәһра** да бар. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәселе нәкъ менә аңа бәйле рәвештә сакланып калган.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тагын бер хатыны – **Гайшә бинте Әбү Бәкер радыяллаһу ганһә** турында да искә алу мөмкин түгел. Яшь булуына да карамастан, Гайшә радыяллаһу ганһә Пәйгамбәребезнең сәхабәләре арасында зур абруй казанган. Шактый катлаулы дини һәм сәяси мәсьәләләрне тикшерүдә һәм карарлар чыгаруда катнашкан.

Гайшә радыяллаһу ганһә гыйлем алуга да зур игътибар биргән, Пәйгамбәребезнең күп хәдисләрен һәм гамәлләрен истә калдырган. Аның гыйлеме турында сәхабәләр түбәндәге сүзләрне әйткәннәр: “Гайшәнең гыйлемен җыеп, аны башка хатын-кызлар гыйлеме белән чагыштырсаң, Гайшәнең гыйлеме өстенрәк булыр иде. Безгә нинди дә булса хәдис аңлашылмаса, без аның турында Гайшәдән сорый идек һәм һәрвакытта да җавап таба идек”. Гайшә радыяллаһу ганһә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән 2210 хәдис тапшырган.

**Зәйнәб бинте Гали** – пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең оныгы, Фатыйма һәм Гали бине Әбү Талибның кызы. Зәйнәб бинте Гали Әһле Әл-Бәйтнең (Пәйгәмбәребез гаиләсенең) иң тәкъва һәм күренекле кешеләре арасында булып, Кәрбаладагы (Гыйрактагы шәһәр) сугышта төп рольне уйнаган. Бу сугышта өммәвиләр тарафыннан аның бертуганы Әл-Хөсәен бине Гали һәм 70 абзасы һәм туганнан туган энеләре үтерелә. Бу вакыйгалардан соң күп еллар дәвамында Зәйнәб бинте Гали Әһле Бәйтнең җитәкчесе булып торган, туганы Хөсәеннең эшен дәвам иттергән. Куфа шәһәрендә туганнан туган энесе, Хөсәеннең улы – Гали бине Әл-Хөсәенне үлемнән саклап калган, судта нотык тоткан. Бу нотыктан соң хәлифә Кәрбаладагы тоткыннарны азат иткән. Зәйнәб бинте Гали үзенең көчлелеге, сабырлыгы һәм зирәклеге белән башкалардан аерылып торган.

Ислам тарихында үз эзләрен калдырган мөслимәләр белән беррәттән, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышын саклап калырга ярдәм иткән нәфис гүзәл затлар, ләкин шул ук вакытта тәвәккәл булган мөслимәләрнең исемнәрен искә алу да урынлы булыр.

“Бервакыт сәфәрдә чагында пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм дөяләргә утырган берничә хатын-кызны күргән. Дөяләрне йөртүче шулчаклы кызу куалаган, хатын-кызларга бу шактый уңайсызлыклар тудыруы хакында да уйламаган. Шулвакытта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа: “Син бәллүр тартмачыклар алып барасың, берүк алар белән саграк бул!” – дип әйткән.

Беренче мөслимәләр, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең замандашлары, “Ләә иләәһә илләллаһ Мухәммәдүр расүлуллаһ” (“Аллаһыдан башка илаһ юк, Мөхәммәд – Аллаһының Расүле”) кәлимәсенең мәгънәсен башкаларга караганда да ныграк аңлаганнар.

Мәккә мөшрикләре Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне үз урынында йоклаган вакытында үтерергә ниятләгәндә, нәкъ менә **Нәфит Гали Гыйльмийә** исемле мөслимә Пәйгамбәребезнең гомерен саклап калган. Ул дошманнарның үзара сүз куешканнары хакында белеп, бу турыда Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә хәбәр биргән. Дошманнары аны йоклаган дип белсеннәр өчен, Аллаһының Расүле үз йокы бүлмәсенә Гали бине Әбү Талибны калдырып, төн караңгылыгында Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе белән Мәккәдән чыгып киткән. Алар юлга җәяүләп чыкканнар. Дошманнарны юлдан яздыру өчен, Мәдинә ягына – төньякка түгел, ә Йәмәнгә таба киткәннәр. Аннан соң Сәвер дип аталган мәгарәгә кереп яшеренгәннәр. Һәр төн саен Әбү Бәкер радыяллаһу ганһенең кызы **Әсма** аларга ризыклар китергән, аларны эзләүчеләр хакында яңа хәбәрләрне ирештереп торган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне һәм этисен саклау максатыннан бу яшь мөслимә бервакыт төнлә биек тауга күтәрелгән. Тирә-яктагы дошманнар һәм тынгысыз бу җирлек тә куркытмаган аны. Бервакыт корәешлеләр юлына чыгып, аны әйләндереп алганнар, сорау үткәргәннәр. Ләкин ул куркып калмаган, сер бирмәгән. Араларыннан берәү йөзенә сугып, колакларындагы алкаларын тарта башлаган. Мондый мәсхәрәләргә дә түзгән ул, бернәрсә дә сөйләмәгән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән этисе Мәдинәгә юл тотканчыга кадәр Әсма аларга гел ризык китереп торган.

**Әсма бинте Өмәйс** – Җәгъфәр бине Әбү Талибның хатыны, ире белән беррәттән Ислам динен кабул иткән. Үз диннәренә тугрылыкны саклау максатыннан үз яшәгән җирләрен калдырып, ире белән Хәбәшәгә һиҗрәт кылган.

**Сөмәйә өмми Гаммәр бине Ясир** – шулай ук Ислам дине хакына үз гомерен кызганмаган. Аның гаиләсен камчы белән җәзалаганнар, үлем якынлашуын сизсен өчен башларын суга тыкканнар. Ләкин алар диннәреннән баш тартмаганнар. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм аларның хәлләрен белеп болай дип әйткән: “Түзегез, Ясир гаиләсе, сезгә оҗмах вәгъдә ителгән”.

**Нәсибә бинте Кәгъб Әл-Мәсинил өмми Гомәр** – сәхабә хатын-кызларның берсе. Бер бәрелеш вакытында ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килеп кушылган. Шулай бервакыт, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә куркыныч янаган вакытта, Аллаһының Расүлен саклау максатыннан, ул бер адым алгарак чыккан. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кайсы якка гына борылса да, гел аны яклап алдына Нәсибә чыга торган булган.

Көннәрнең берендә Нәсибәнең улы Гомәр яраланган. Әнисе улының яралы җилкәсен бәйләгән дә: “Тор, улым, туктап калма, ахыргача көрәш!” – дип әйткән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аның бу батырлыгына һәм көчлелегенә сокланып: “Гомәрнең әнисе кылганнарны йә тагын кайсыгыз булдыра ала?” – дип сораган. Шул көнне Нәсибә ялардан үзе дә хәлсезләнгән һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән үзе һәм улы өчен дога кылуын үтенгән. Аллаһының Расүле аның үтенечен кабул итеп, Аллаһы Тәгаләгә дога кылган. Нәсибә бик шат булган, ул бернәрсәдән дә курыкмаган.

Күргәнебезчә, Аллаһыга чынлап ышанган бу кешеләрне – гүзәл хатын-кызларны бернәрсә дә куркытмаган. Тән җәзалары да, рухи яктан кысрыклаулар да тәэсир итмәгән аларга. Алар Аллаһы хакына түзгәннәр. Без дә алардан үрнәк алып, динебезгә һәм телебезгә тугры булсак иде.

■ ***Сәхифәне Лилия Хәләфетдинова әзерләде***

# Кайнар диңгез юлы



Тәрәзәдән кергән әрсез салкын җил улаган тавышка Таһир сискәнеп уянды. Туңудан калтыранган тәне җылы эзләп, өстенә юрганын ике катлап япты. Бер кешелек тимер караватка җәелгән юка матрас аша идәннән күтәрелгән салкын җил аның җанына-бәгыренә үтә. Ул юрганына уралган килеш, урыныннан торды. Тәрәзә пәрдәсен күтәреп, тышка карады. «Йә Раббым!» – диде ул. Май аенда кап-караңгы төнне яктыртып ишелеп-ишелеп кар ява. Тәне калтыранып куйды, башында кайнаган уйлар өермәсе аша күзен йомды... Ул менә икенче атнасын тулай торакның ун квадрат метрлы бүлмәсендә үткәрә. Кичә дә көне буе бер үзе булды. Нигә аны җитәкчеләр үз яннарына чакырып сөйләшмиләр? Каршы алдылар, шушында китереп урнаштырдылар да, үзләре сүзсез генә китеп югалдылар. Оныттылармы әллә Таһирне? Югыйсә, Татарстан Диния Нәзарәте тарафыннан Сургут җирендә динне күтәрергә дип җибәрелгән юлламасын шатланып кабул иткән кебек тоелдылар ич. Бүген дә чакыручы булмаса? Өстендә дә юка кием генә. Себернең салкын җиле аның костюмы аша үтеп, тәнен өшетеп туңдыра. Әгәр ул мондагы салкынга түзә алмаса?.. Таһирның үзгән өзеп сагыну хисе биләп алды, кайтасы килә башлады... Куллары белән үз-үзен кочаклады. Күз алдына нәфис җан иясе, беренче саф мәхәббәте, хәләл хатыны Рәйсәсе килеп басты. Аның илаһи матурлык белән карый торган күзләренә төбәлгәндәй булды, йомшак тавышын ишетте. Ул аңа: «Таһирем, ник Зөһрәңне ялгыз калдырып киттең, мин синсез ничек яшим? Кайт, бәгърем, нинди зур Казаныбызда синең кебек тәкъва имамнарга урын табылыр. Кайт...» – дип эндәшә, чакыра кебек. Әниләренең муенына сарылган кызы Әлфинурының аңа яшьле күзләре төбәлде. Ул да үпкәле кебек. Шушы ике илаһи зат иясен унике яшьлек улы Камил тынычландыра сыман тоела. Таһирне тимер юл вокзалына озатырга килгәч: "Җәйге каникулга чыккан көнне үк, Себергә килеп җитәрбез, әти", – дип, саубуллашкан иде. Шулчакта барысының да күзе дымланды. Ә Камил тәкъвалыгын күрсәтеп, күз яшен эчкә йотты. Улының, әле яшүсмер малай гына булса да, шул минутта әтисенә карата теләктәшлек күрсәтүе, муенына сарылып еларга керешмәве, аны берьяктан куандырды. Тик, шушы минутта, ул балаларына да кирәк. Бу салкын бүлмәдә тагын күпме ятарга тиеш? Әгәр дә иртәгә дә бернинди үзгәреш булмаса, кайтып китәчәк ул. Монда имам кирәк булса, аны шул көнне үк чакыртып алып, уй-фикерләре белән уртаклашырга тиешләр иде...

Таһир уй-хыялында кулына кечкенә чемоданын тотып, туган ягына кайтып китәргә җыенды. Шулчак: әтисе Татарстанның баш казые, Габделхак хәзрәт Саматовның: «Тукта, улым! Үзеңнең Аллаһ юлында хезмәт итәргә киткәнеңне исеңнән чыгарма! Кирегә юл юк! Син – Себер җиренә Аллаһның илчесе итеп җибәрелдең. Безнең милләттәшләребез дөньяның бар кыйтгасына таралган. Шулар арасыннан Аллаһның сөекле бәндәләрен эзләп тап. Ул кешеләрдән сиңа җылы җил исәр, Аллаһ сиңа аларны йогышлы сүзләре, җылы мөнәсәбәтләре аша белгертер...». Таһир сискәнеп китте. Нәрсә бу?! Әтисе аның янәшәсендә генә кебек. Тавышы да кара-каршы басып сөйләшкән кебек.

Таһир уйларын тәртипкә салды. Ул, шушы мизгелдә әтисенең дә аны уйлап, аның өчен борчылып, йокысыз төн үткәргәнен йөрәге, акылы белән тойды. Карават читенә барып ятуга, аны уйлар өермәсе бөтереп алды...

...Алар гаиләдә дүрт бала үсте. Бик гади, уртача гына тормышта яшәделәр. Унбер ел әтисенең бертуган абыйсы Кәнзелголум гаиләсе белән бер баракта кысан гына бүлмәләрдә яшәгән вакытларын искә төшерде. Ике ояга ун бала шунда әүмәкләшеп үстеләр. Әти-әниләре көне буе эштә. Абыйсы белән әнисе бер заводта эшләделәр. Күз алдына тыйнаклыгы, әдәп- әхлакның үрнәге булган әнисе килеп басты. Ул кырык ел хәтта Кәнзелголум абыйдан да тел яшерде. Әйтәсе килгән сүзен дә аңа Шакирә җиңги аша җиткерде. Унбиш кешелек гаилә абыйлары сүзеннән чыкмады. Акча да аның кулында булды. Татар гаиләсендә борынгыдан, акча бер кеше кулында гына булырга тиеш дигән тәртип сакланган. Ике оя бала әти-әниләре үрнәгендә кече яшьтән намаз укыды. Бер Аллаһны гына танырга, Аңа гына гыйбадәт кылырга, берәүне дә ширек кылмаска кирәклеген каннарына сеңдереп үстерде. Әтисенең һәр гамәлен, әйткән сүзләрен исенә төшерде. Колак төбендә аның ягымлы тавышын ишетә... Хәтер хәзинәсе аша үткәнне әйләндерә башлады.

...Әнә, ул апалары белән бергә тәһарәт ала. Әтиләре аларны күзәтеп тора. "Терсәкләрегезне әйбәтләп, өч кат юыгыз. Сәбабы үзегезгә күбрәк булыр", – дип өйрәтә. Аңа әнисе Кәүсәриянең йомшак тавышы ялганды. "Ястү намазыннан соң, яңадан бер тапкыр сәҗдәгә китеп, Аллаһтан үзегезгә бәхет-һидаят сорагыз, балалар!"...

Унынчы сыйныфны тәмамлагач, Таһирне әтисе үзе белән Лаеш районында яшәүче Борһан дустына кунакка алып барды. Техникумда белем алучы кызы Рәйсә аларга аш чыгарды. Ул аларга керфеген дә күтәреп карамады. Хан кызы кебек тоелды ул Таһиргә. Беренче тапкыр күргән көнне үк, кыз аның йөрәгендә үз урынын алды. Армиягә чакыру кәгазе килгәч, Рәйсәне күрер өчен, әтисе белән янә аларга барды. Кызның үзен генә туры китереп: "Хәрби бурычымны үтәп кайтуга, Казанга алып китәм мин сине гүзәл кыз", – дип пышылдады. Рәйсә комач кебек кызарды. Таһир аның адресын сорап алды. Өч ел егет белән кыз арасын тыйнак кына язылган хатлар тоташтырды. Таһир көз көне армиядән кайтты, гыйнвар уртасында никахлаштылар...

Әти-әнисе Әлмәткә күченеп киттеләр. Ул Рәйсә белән Волгоград урамындагы ике бүлмәле фатирларында яши башлады. Хатыны эшкә аптекага урнашты, ә Таһир төзелештә кранда эшләде. Уллары Камил шул йортта туды. Тудыру бүлегеннән алып кайткан көнне үк, Таһир Каравай бистәсеннән җир сатып алды һәм алар үзләренә җыйнак кына йорт салдылар. Яңа йортта кызлары Әлфинур туды. Тормыш түгәрәкләнде. Малай чактан дини рухта тәрбияләнгән ир белән хатын үзләрендә гыйлем җитмәвен аңладылар. Рәйсә "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенә керде, ә Таһиргә әтисе Төркиягә барып укырга киңәш итте. Ата сүзенә каршы килергә өйрәнмәгән ир, гаиләсен калдырып, укырга китте. Чит илдә ике ел белем алды. Гаиләсе белән елга дүрт-биш тапкыр гына күрештеләр. Сабырлык дигәндә, тиңдәше булмаган Рәйсәсе, ике баланы бер үзе тәрбияләде. Төркиядән укып кайткач, Таһир читкә китәргә җыенмаган иде. Әтисе –Татарстанның баш казые Габделхак Саматов, Себергә үз улын җибәрер дип, уена да китермәде. Каршы килеп тә маташты. "Себергә синең кебек чит илдә белем алган гыйлемле имам гына тәкъдим итеп була. Каршы килмә, улым, барасың булгач, барасың!" – диде, катгый итеп. "Син кушкач, килдем, әти. Аллаһ ташламас әле", – диде үз-үзенә.

*Дәвамы киләсе санда*

■ **Гөлсинә Галимуллина, "Кайнар диңгез юлы" повестеннән өзек**

■ ДҮШӘМБЕ
07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Тәмле булсын
08:20 «Сүз эчендә хикмәт бар»
08:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
09:00 Әлифба сабаклары
09:15 Һөнәрләр
09:30 «Таз Малай» мультфильм
09:45 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
09:55 Бер мәчет тарихы
10:05 Бәрәкәтле гаилә
10:55 «Пәйгамбәр сүзе эзеннән»
11:30 Хәдис дәресләре
11:50 «Иң гүзәл исемнәр»
12:00 Азан
12:05 Учимся читать намаз
12:30 МИМ
12:40 Самые прекрасные имена
12:50 Разговоры о важном
13:00 «Шекер Ходжа» мультфильм
13:15 «Малец-Удалец» мультфильм
13:30 Поучительные истории
13:40 «По следам пророческого откровения»
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәмле булсын
17:20 «Сүз эчендә хикмәт бар»
17:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
18:00 Әлифба сабаклары
18:15 Һөнәрләр
18:30 «Таз Малай» мультфильм
18:45 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
18:55 Бәрәкәтле гаилә
19:45 «Иң гүзәл исемнәр»
19:55 «Пәйгамбәр сүзе эзеннән»
20:30 Хәдис дәресләре
20:50 Бер мәчет тарихы
21:00 «Шекер Ходжа» мультфильм
21:15 «Малец-Удалец» мультфильм
21:30 Поучительные истории
21:40 «Самые прекрасные имена»
21:50 «Разговоры о важном»
22:00 Учимся читать намаз
22:20 МИМ
22:30 Хузур вояж с Антоном Кротовым
22:40 «По следам пророческого откровения»
23:20 Художественный фильм
01:00 Чтение Священного Корана

■ СИШӘМБЕ
07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Хәзинә
08:20 «Сүз эчендә хикмәт бар»
08:30 «Таз Малай» мультфильм
08:45 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
09:00 «Иң гүзәл исемнәр»
09:10 Мавлид ан-Наби И.Хасанов
10:00 Намазга өйрәник
10:20 Бер хәдис – бер җавап
10:30 "Тәфсир дәресләре" Тимергали Юлдашев
11:00 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
11:15 Гаилә дәресләре
11:45 Мукабаля (Чтение Корана)
12:00 Азан
12:05 Актуальный ислам
12:20 Самые прекрасные имена
12:30 "Шекер Ходжа" мультфильм
12:40 «Малец-Удалец» мультфильм
13:00 Ученые Ислама
13:20 Есть вопрос – есть хадис
13:40 Мавлид ан-Наби С.Мурадимов
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Хәзинә
17:20 «Сүз эчендә хикмәт бар»
17:30 «Таз Малай» мультфильм
17:45 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
18:00 «Иң гүзәл исемнәр»
18:10 Мавлид ан-Наби
19:00 Намазга өйрәник
19:20 Бер хәдис – бер җавап
19:30 "Тәфсир дәресләре" Тимергали Юлдашев
20:00 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
20:15 Гаилә дәресләре
20:45 Мукабаля (Чтение Корана)
21:00 «Шекер Ходжа» мультфильм
21:15 «Малец-Удалец» мультфильм
21:30 Актуальный ислам
21:50 Самые прекрасные имена
22:00 Ученые Ислама
22:20 Есть вопрос – есть хадис
22:40 Мавлид ан-Наби
23:20 Художественный фильм
01:05 Чтение Священного Корана

■ ЧӘРШӘМБЕ
07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Тәмле булсын
08:20 «Сүз эчендә хикмәт бар»
08:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
09:00 Әлифба сабаклары
09:15 Һөнәрләр
09:30 «Таз Малай» мультфильм
09:45 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
09:55 Бер мәчет тарихы
10:05 Бәрәкәтле гаилә
10:55 «Пәйгамбәр сүзе эзеннән»
11:30 Хәдис дәресләре
11:50 «Иң гүзәл исемнәр»
12:00 Азан
12:05 Учимся читать намаз
12:30 МИМ
12:40 Самые прекрасные имена
12:50 Разговоры о важном
13:00 «Шекер Ходжа» мультфильм
13:15 «Малец-Удалец» мультфильм
13:30 Поучительные истории
13:40 «По следам пророческого откровения»
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәмле булсын
17:20 «Сүз эчендә хикмәт бар»
17:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
18:00 Әлифба сабаклары
18:15 Һөнәрләр
18:30 «Таз Малай» мультфильм
18:45 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
18:55 Бәрәкәтле гаилә
19:45 «Иң гүзәл исемнәр»
19:55 «Пәйгамбәр сүзе эзеннән»
20:30 Хәдис дәресләре
20:50 Бер мәчет тарихы
21:00 «Шекер Ходжа» мультфильм
21:15 «Малец-Удалец» мультфильм
21:30 Поучительные истории
21:40 «Самые прекрасные имена»
21:50 «Разговоры о важном»
22:00 Учимся читать намаз
22:20 МИМ
22:30 Хузур вояж с Антоном Кротовым
22:40 «По следам пророческого откровения»
23:20 Художественный фильм
01:00 Чтение Священного Корана

■ ПӘНҖЕШӘМБЕ
07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Хәзинә
08:20 «Сүз эчендә хикмәт бар»
08:30 «Таз Малай» мультфильм
08:45 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
09:00 «Иң гүзәл исемнәр»
09:10 Мавлид ан-Наби И.Хасанов
10:00 Намазга өйрәник
10:20 Бер хәдис – бер җавап
10:30 "Тәфсир дәресләре" Тимергали Юлдашев
11:00 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
11:15 Гаилә дәресләре
11:45 Мукабаля (Чтение Корана)
12:00 Азан
12:05 Актуальный ислам
12:20 Самые прекрасные имена
12:30 "Шекер Ходжа" мультфильм
12:40 «Малец-Удалец» мультфильм
13:00 Ислам без стереотипов
13:20 Халяль-лайфстайл
13:40 Мавлид ан-Наби С.Мурадимов
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Хәзинә
17:20 «Сүз эчендә хикмәт бар»
17:30 «Таз Малай» мультфильм
17:45 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
18:00 «Иң гүзәл исемнәр»
18:10 Мавлид ан-Наби
19:00 Намазга өйрәник
19:20 Бер хәдис – бер җавап
19:30 "Тәфсир дәресләре" Тимергали Юлдашев
20:00 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
20:15 Гаилә дәресләре
20:45 Мукабаля (Чтение Корана)
21:00 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
21:15 «Малец-Удалец» мультфильм
21:30 Актуальный ислам
21:50 Самые прекрасные имена
22:00 Ислам без стереотипов
22:20 Халяль-лайфстайл
22:40 Мавлид ан-Наби
23:20 Художественный фильм
01:05 Чтение Священного Корана

■ ҖОМГА
07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Тәмле булсын
08:20 «Сүз эчендә хикмәт бар»
08:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
09:00 Әлифба сабаклары
09:15 Һөнәрләр
09:30 «Таз Малай» мультфильм
09:45 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
09:55 Бәрәкәтле гаилә
10:45 «Пәйгамбәр сүзе эзеннән»
11:20 «Иң гүзәл исемнәр»
11:30 Минбар
12:00 Азан
12:05 Учимся читать намаз
12:30 МИМ
12:40 Самые прекрасные имена
12:50 Разговоры о важном
13:00 «Шекер Ходжа» мультфильм
13:15 «Малец-Удалец» мультфильм
13:30 Поучительные истории
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәмле булсын
17:20 «Сүз эчендә хикмәт бар»
17:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
18:00 Әлифба сабаклары
18:15 Һөнәрләр
18:30 «Таз Малай» мультфильм
18:45 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
18:55 Бәрәкәтле гаилә
19:45 «Пәйгамбәр сүзе эзеннән»
20:20 «Иң гүзәл исемнәр»
20:30 Минбар
21:00 «Шекер Ходжа» мультфильм
21:15 «Малец-Удалец» мультфильм
21:30 Поучительные истории
21:40 Самые прекрасные имена
21:50 Разговоры о важном
22:00 Учимся читать намаз
22:20 МИМ
22:30 Хузур вояж с Антоном Кротовым
22:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
23:20 Художественный фильм
01:00 Чтение Священного Корана и толкование на татарском языке

■ ШИМБӘ
07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Тәмле булсын
08:20 «Сүз эчендә хикмәт бар»
08:30 Балам-багалмам
08:50 «Иң гүзәл исемнәр»
09:00 «Таз Малай» мультфильм
09:15 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
09:30 Хәзинә
09:45 Һөнәрләр
10:00 Намазга өйрәник
10:30 Әлифба сабаклары
10:45 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
11:00 «Мәслихәт»
11:20 Хәдис дәресләре
11:40 Мукабаля (Чтение Корана)
12:00 Азан
12:05 Актуальный ислам
12:20 Самые прекрасные имена
12:30 "Шекер Ходжа" мультфильм
12:40 «Малец-Удалец» мультфильм
13:00 Ислам без стереотипов
13:20 Халяль-лайфстайл
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәмле булсын
17:20 «Сүз эчендә хикмәт бар»
17:30 Балам-багалмам
17:50 «Иң гүзәл исемнәр»
18:00 «Таз Малай» мультфильм
18:15 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
18:30 Хәзинә
18:45 Һөнәрләр
19:00 Намазга өйрәник
19:30 Әлифба сабаклары
19:45 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин, фикһ дәресләре
20:00 «Мәслихәт»
20:20 Хәдис дәресләре
20:40 Мукабаля (Чтение Корана)
21:00 «Шекер Ходжа» мультфильм
21:15 «Малец-Удалец» мультфильм
21:30 Актуальный ислам
21:50 Самые прекрасные имена
22:00 Ислам без стереотипов
22:20 Халяль-лайфстайл
22:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
23:20 Художественный фильм
01:05 Чтение Священного Корана

■ ЯКШӘМБЕ
07:00 Хәерле сәгатьтә
08:00 Тәмле булсын
08:20 «Сүз эчендә хикмәт бар»
08:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
09:00 Әлифба сабаклары
09:15 Һөнәрләр
09:30 «Таз Малай» мультфильм
09:45 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
10:00 Бер мәчет тарихы
10:10 Бәрәкәтле гаилә
11:00 «Иң гүзәл исемнәр»
11:10 Хәдис дәресләре
11:30 Минбар
12:00 Азан
12:05 Учимся читать намаз
12:30 МИМ
12:40 Самые прекрасные имена
12:50 Разговоры о важном
13:00 «Шекер Ходжа» мультфильм
13:15 «Малец-Удалец» мультфильм
13:30 Поучительные истории
13:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Тәмле булсын
17:20 «Сүз эчендә хикмәт бар»
17:30 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт
18:00 Әлифба сабаклары
18:15 Һөнәрләр
18:30 «Таз Малай» мультфильм
18:45 «Шөкер Хуҗа» мультфильм
19:00 Бер мәчет тарихы
19:10 Бәрәкәтле гаилә
20:00 «Иң гүзәл исемнәр»
20:10 Хәдис дәресләре
20:30 Минбар
21:00 «Шекер Ходжа» мультфильм
21:15 «Малец-Удалец» мультфильм
21:30 Поучительные истории
21:40 Самые прекрасные имена
21:50 Разговоры о важном
22:00 Учимся читать намаз
22:20 МИМ
22:30 Хузур вояж с Антоном Кротовым
22:40 «Мусульмане, которыми гордится Россия». Документальный фильм
23:20 Художественный фильм
01:00 Чтение Священного Корана и толкование на татарском языке

# КАЗАН ӨЧЕН ДЕКАБРЬ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Көн Исеме | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы/ифтар | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | |
| 01.12.2020 | Сиш | 05:32 | 06:19 | 07:49 | 12:00 | 13:27 | 15:15 | 17:10 |
| 02.12.2020 | Чәрш | 05:33 | 06:20 | 07:50 | 12:00 | 13:26 | 15:14 | 17:10 |
| 03.12.2020 | Пәнҗ | 05:34 | 06:22 | 07:52 | 12:00 | 13:26 | 15:14 | 17:09 |
| 04.12.2020 | Җом | 05:35 | 06:23 | 07:53 | 12:00 | 13:25 | 15:13 | 17:09 |
| 05.12.2020 | Шим | 05:36 | 06:25 | 07:55 | 12:00 | 13:25 | 15:12 | 17:09 |
| 06.12.2020 | Якш | 05:37 | 06:26 | 07:56 | 12:00 | 13:24 | 15:12 | 17:08 |
| 07.12.2020 | Дүш | 05:39 | 06:28 | 07:58 | 12:00 | 13:24 | 15:11 | 17:08 |
| 08.12.2020 | Сиш | 05:40 | 06:29 | 07:59 | 12:00 | 13:23 | 15:11 | 17:08 |
| 09.12.2020 | Чәрш | 05:41 | 06:30 | 08:00 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 |
| 10.12.2020 | Пәнҗ | 05:42 | 06:32 | 08:02 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 |
| 11.12.2020 | Җом | 05:43 | 06:33 | 08:03 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 |
| 12.12.2020 | Шим | 05:44 | 06:34 | 08:04 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 |
| 13.12.2020 | Якш | 05:44 | 06:35 | 08:05 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 |
| 14.12.2020 | Дүш | 05:45 | 06:36 | 08:06 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 |
| 15.12.2020 | Сиш | 05:46 | 06:37 | 08:07 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 |
| 16.12.2020 | Чәрш | 05:47 | 06:38 | 08:08 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 |
| 17.12.2020 | Пәнҗ | 05:48 | 06:38 | 08:08 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:08 |
| 18.12.2020 | Җом | 05:48 | 06:39 | 08:09 | 12:00 | 13:23 | 15:10 | 17:09 |
| 19.12.2020 | Шим | 05:49 | 06:40 | 08:10 | 12:00 | 13:24 | 15:11 | 17:09 |
| 20.12.2020 | Якш | 05:49 | 06:41 | 08:11 | 12:00 | 13:24 | 15:11 | 17:10 |
| 21.12.2020 | Дүш | 05:50 | 06:41 | 08:11 | 12:00 | 13:25 | 15:11 | 17:10 |
| 22.12.2020 | Сиш | 05:50 | 06:42 | 08:12 | 12:00 | 13:25 | 15:12 | 17:11 |
| 23.12.2020 | Чәрш | 05:51 | 06:42 | 08:12 | 12:00 | 13:26 | 15:13 | 17:11 |
| 24.12.2020 | Пәнҗ | 05:51 | 06:42 | 08:12 | 12:00 | 13:26 | 15:13 | 17:12 |
| 25.12.2020 | Җом | 05:52 | 06:43 | 08:13 | 12:00 | 13:27 | 15:14 | 17:13 |
| 26.12.2020 | Шим | 05:52 | 06:43 | 08:13 | 12:00 | 13:28 | 15:15 | 17:13 |
| 27.12.2020 | Якш | 05:52 | 06:43 | 08:13 | 12:00 | 13:29 | 15:16 | 17:14 |
| 28.12.2020 | Дүш | 05:52 | 06:43 | 08:13 | 12:00 | 13:30 | 15:17 | 17:15 |
| 29.12.2020 | Сиш | 05:53 | 06:43 | 08:13 | 12:00 | 13:31 | 15:18 | 17:16 |
| 30.12.2020 | Чәрш | 05:53 | 06:43 | 08:13 | 12:00 | 13:32 | 15:19 | 17:17 |
| 31.12.2020 | Пәнҗ | 05:53 | 06:43 | 08:13 | 12:00 | 13:33 | 15:20 | 17:18 |

**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**
*Ноябрь саны, №11 (304)*

Баш мөхәррир: **Нәширбанов И.К.**
Мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;
ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБАРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2755
Газетага ярты елга язылу бәясе – 156 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 24 нче ноябрьдә таратыла.
График буенча бу санга 23 нче ноябрь көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.